«Яхшыга өметләнгән идек, әмма...»

яки авыл хуҗалыгы тармагы бүген нинди авырлык кичерә?

Моңа кадәр җитәкчеләр, язгы кыр эшләренә әзерлек мәсьәләсендә берникадәр проблемалар булса да, гомуми хәл яхшы, дип белдереп килде. Әмма шушы көннәрдә телдән төшмәгән тагын бер мәсьәлә баш калкытты...

7 БИТ

Эльмира Кәлимуллина: «Сәхнә – бокс рингы түгел»

«Сәхнә бит ул бокс рингы түгел, анда көндәшне егып салырга кирәкми. Анда чыгып, үзең өчен җиренә җиткереп җырларга гына кирәк».

12 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 30.03.2017 | № 33 (5795) www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА: СОРАУЛАР ҺӘМ ҖАВАПЛАР

2005 елдан 2016 елга кадәр республикада социаль ипотека программасы буенча барлыгы 118 мең гаилә тораклы булган. Бу өлкәдәге үзгәрешләр турында гел язып торсак та, программадагы яңалыкларны халыкка җентекләп аңлатсак та, социаль ипотекага кагылышлы сораулар редакциябезгә еш килә. Сорауларга Татарстан Президенты каршындагы Торак фондының мәгълүмат сәясәте төркеме җитәкчесе Лилия Маннапова җавап бирә.

5 БИТ

kazan.kp.ru

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга — 66 сум 99 тиен
3 айга — 200 сум 97 тиен
6 айга — 401 сум 94 тиен

Ташламалы бәядән язылып кал!

һәр айның 15 числосына кадәр язылсагыз, газета киләсе ай башыннан киләчәк.

Синең өчен, синең турында!

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

136 сум 15 тиен — 1 айга
408 сум 45 тиен — 3 айга
816 сум 90 тиен — 6 айга

Реклама

РЕСПУБЛИКАДА

ЛЕНИНОГОРСК

Шәһәрнең Үзәк мәйданында Нәүрүз бәйрәме үтте. Бәйрәм театральләштерелгән күренештән башланып китте. Районда яшәүче төрки халыклар үзләренең аш-сулары белән сыйлады. Балалар өчен төрле уеннар оештырылган иде.

ӘЛМӘТ

Әлмәт шәһәре күлендә Бөек Җиңүнең 72 еллыгына багышлап «Җиңүгә кадәр йөзәргә» Бөтенроссия акциясе кысаларында марафон йөзүе башланды. Әлеге акциядә катнашырга Уфа, Можга «морж»лары да килде. Бозлы суга беренче булып 80 яшьлек Михаил Землянов керде. Дистанцияне район башлыгы Айрат Хәйруллин да узды.

АПАС

«Туган якны өйрәнү» үзәк музее каршында палеонтология музее ачылачак. Иң кыйммәтле экспонат булачак үз зурлыгындагы ана мамонт һәм аның баласы карачкыларының беренчел эскиз-скелетлары әзер. Аларның казык тешләре, кабыргаларының, баш казнасының кайбер элементлары районда төрле елларда табылган. Район территориясендә 50 еллар элек археологлар казып чыгарган динозавр скелеты да шушы ук залга урнаштырылачак.

ЧҮПРӘЛЕ

Иске Чүпрәле урта мәктәбендә укучыларның «Иҗади тылсым дөньясы» кул эшләнмәләре фестивале узды. Ул Пионер оешмасы барлыкка килүнең 95 еллыгына багышланган иде. Шуңа да биредә пионер тормышына кагылышлы атрибутлар аерым урынны алып торды. Кемнәрдер шул чордагы галстукларны пөхтә итеп күргәзмәгә куйган, кайсыларыдыр бырғы, барабаннарга кадәр тапкан. Шулай ук күргәзмәдә балчыктан, тозлы камырдан, төсле кәгазьләрдән ясалган кул эшләнмәләре күп иде.

НУРЛАТ

Агымдагы елда «Ятим балаларны торак белән тәэмин итү» республика программасы кысаларында, Нурлат районында 18 ятим фатир алачак. Фатирлар яңа йортлардан гына тапшырыла. Ятимнәргә бүленеп бирeләчәк торак мәсьәләсен район башлыгы Равил Кузюров үз контролендә тота. Программаны үтәү вакыты августка билгеләнгән.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

vladtime.ru

Буранмы? Димәк, яз килде!

Быелгы кыш бигрәк үҗәт булып чыкты, һич китәргә ашыкмый. Бүген-иртәгә апрель башлана дип торганда, кар көрәп йөр инде. Кыенсыну дигән нәрсә бер дә юк икән үзендә, рәхәтләнеп бураннарын дулата. Орнитолог, биология фәннәре докторы Илгизәр Рәхимов сүзләренчә, бу кышның иң соңгы – сыерчык бураны.

– Бу вакытка сыерчыклар кайтып җитәргә тиеш иде инде, авыл җирендә, бәлки, күрүчеләр дә бардыр, шәхсән үземнең әлегә күргәнем юк. Гадәттә алар, көннәр суытып җибәргәч, юлда туктап торалар. Аннары инде барысы бергә бер көндә дә очып килергә мөмкин. Тургайлар да бу вакытка кайткан булырга тиеш. Борчылмагыз, сыерчык бураны язның килүен хәбәр итә, – дип тынычландырды безне ул.

Шушы көннәрдә Татарстанның Гидрометеорология үзәге сайтында 2017 елның вегетация чорына: апрельдән сентябрьгә кадәрге һава шартлары турысы буенча фаразлар барлыкка килде. Андагы мәгълүматлардан күренгәнчә, апрель, май, июнь һәм август айларында һаваның уртача температурасы норма буенча булачак. Июль аенда исә гадәттәгедән эссе булыр дип көтелә, ә явым-төшемнәр нормага якын булыр дип фаразлана. Сентябрь дә эссе килергә охшаган. Һава температурасы шулай ук нормадан җылырак булачак. Явым-төшем дә нормадан күбрәк көтелә.

Галимнәрне исә климатның җылынуы борчый. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында булган матбугат очрашуында Татарстанның Гидрометеорология үзәге җитәкчесе Феликс Гоголь хәбәр итүенчә, Татарстанда метеорологлар температураның үзгәрмичә артып баруын билгеләгән. Әлеге күренеш уртача еллык күрсәткечләрдә генә түгел, аерым айларда да күзәтелә.

– Элеккечә үк Татарстанда климат җылыну дәвам итә – һәр ун ел саен Цельсий буенча уртача 0,34 градус тизлектә җылына. Бу – 1951-2016 еллар аралыгында булган хәл. Узган гасырның 70нче еллар уртасыннан уртача еллык һава температурасы 0,54 градус тизлек белән тизрәк күтәрелә башлаган. Бу – сизелерлек дәрәҗәдәге үсеш. Димәк, йөз ел дәвамында температура уртача 3,5 градуска арта. Бүген, әйтик, 5 градус булса, тагын йөз елдан шушы вакытта инде 8,5 градус булачак, – дип сөйләгән температура үзгәрешләре турында Феликс Гоголь.

Аның фикеренчә, климат үзгәрүе сәбәпле, яңа культуралар үстерeп булачак, шулай ук туфракны дымлыландыру буенча заманча технологияләр кулланырга кирәк була ала.

2016 ел республика тарихында җылы булуы белән истә калачак. Уртача еллык температура безнең климатта гадәти саналган температурадан 1,9 градуска югары булган.

Шәһәр кәефе

МӘСГУТ ИМАШЕВ,
мөгаллим:

– Пермьдәге Барда районыннан 1958 елда килгән идем Казанга. Рәхмәтле булып яшим, чөнки хезмәтләрем югары бәяләнде. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре исемнәре бирелде. Казан үзенең борынгы вә данлы башкала булуын онытмасын. Тел дә, мәдәният тә милләт тамырларына бәйле. Казан үссен, матурлыгы һәм икътисади куәте белән дөньяга танылсын. Мин гел көй көйләп йөрим, яңа көй.

ӘЛФИНУР САРГУЗИНА,
хезмәткәр:

– Татарстанда Балтач атамасындагы авыллар бик күп икән. Балтач районы, Балык Бистәсе районындагысы, ә мин Кама Тамагындагы Балтач авылыннан. Казанда шактый гомер Авиатөзелеш тармагында эшләдем. Балалар үсеп бетте инде, алар исәнсау булсыннар. Бакчада казынырга яратам, җәйне сагындым. Тегү эшләре дә күңелемә якын, яшь чакта шөгыльләнә идем. Хәзер дә үрнәкләр истә, ләкин күзләр генә начар күрә башлады.

ЭЛЬВИНА ФӘТХЕТДИНОВА,
студент:

– Башкортстанның Уфа шәһәрендә туып-үстем. Мәктәп елларында кунакка килгән чакта ук Казанга гашыйк булган идем. Югары белем алырга ике дә уйламыйча монда килдем. Уфа – туган шәһәрем, ә Казан үзенчә күңелгә якын. Казан Европа дәрәҗәсендә, казанлылар да игътибарлы, мөләем. Икътисадчы белгечлегенә әйбәт кенә укып йөрим. Башкортстанга миннән сәлам! Җәйге каникулда өйгә инде, Алла боерса.

ФӘНЗИЛӘ ТАҺИРОВА,
хезмәткәр:

– Казанда 1972 елдан яшим, Апас районыннан үзем. Баштагы елларда заводта эшләдем. Туган якка кайтып йөрибез, Апасны ничек онытасың ди инде. Уйлар җәй турында инде хәзер: кая барырга? Татарстанның шифаханәләре бик яхшы. Берләшкән Гарәп Әмирлекләрен дә бер күреп кайтасы килә. Киров районының Коләхмәтов урамындагы ишегалларын, йортлар подъездларын төзекләндерсеннәр иде. Иң теләгәнем менә шулар әле.

РӨСТӘМ ИСХАКОВ,
журналист:

– Казанда 2003 елдан хатыным Эльвира белән ике бала үстерәбез. Интернетта татар ашларын пропагандалыйм. Казанда балалар өчен һәр районда «Континент» кебек махсуслаштырылган парклар төзелсен иде. Ул бакча-паркларда яшеллек тә, сабыйларның аң-фикерләвен үстерә торган җиһазлар да булсын иде. Ачык һавадагы математика сыйныфы, мәсәлән. Киләсе җәйдә Кырымга автосәяхәт ясарга ният бар.

Россия паспорты белән Төркиягә

Чит ил паспорты булмаганнар өчен күңелле яңалык: Төркиягә Россия паспорты белән очып булачак. Төркиянең тышкы эшләр министры Мәүлет Чавуш оглы «Эн-ти-ви» телеканалына белдергәнчә, Төркия Россия туристларын эчке паспортлар буенча кабул итәргә әзер.

bloknot.ru

Әлеге уңайдан алар Россия җитәкчелеге белән сөйләшүләр алып барырга җыена, шул ук вакытта үз илләре гражданнарына да шундый мөмкинлек каралуын телиләр, дип яза «Газета.Ru». Моның өчен аэропортларда шәхес таныклыгының эчке өлешен тикшерү буенча җиһазлар куела башлаган.

– Чит ил паспортыннан башка гына кабул итү турында сөйләшүләр ике ил арасындагы мөнәсәбәтләр бозылганчы ук каралырга тиеш иде. Хәзер сөйләшүне яңарту ниятләнелә, – дигән ул телеканал журналистына.

Төркия Россия туристлары иң күп ял итәргә йөргән ил булып тора. Әлеге ил белән үзара аңлашу булганнан соң, ил халкы кабат шунда күпләп оча башлады. Төркия мәдәният министры Авҗи сүзләренчә, быел алар тагын да күбрәк туристлар көтә. Министр 2017 елда туристлар санының артуы узган елгы югалтуларны тулыландырачак дип фаразлый.

Чагыштыру өчен: 2014 елның гыйнварында Төркиядә 51 мең Россия туристы булган, 2015 елда әлеге сан 21 меңгә калган. Туристлар санының күпләп төшүе 2016 елда күзәтелә. 2017 елның гыйнварында гына да Төркиягә 40 меңләп россияле барган.

КҮРШЕЛӘРДӘ

22 июльдә узачак Ык буе авыллары Сабан туена Башкортстанның Туймазы районы Төмәнәк авылында «Бабай утары» этноавылы төзелеп килә. Төмәнәк авылы крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе Фәнир Галимов «Бабай утары»н быел ачарга исәпли. «Авылның 325 еллык тарихын күрсәтәбез. Талдан үрелгән, саман кирпечтән салынган йортларны урнаштырып, туристларны шушында җәлеп итәргә уйлыйбыз. Алар үзләре кымыз савачак, үзләре умарта караячак. Бирегә Ык буе авыллары Сабан туен да үткәрәчәкбез», – дип сөйләгән «Татар-информ» хәбәрчесенә.

Мари Элда «Уңайлы шәһәр мохите булдыру» программасына старт бирелде. Проект кимендә биш елга исәпләнгән. 2017 елны үз эченә алган беренче этапны гамәлгә ашыру өчен 80 миллион сум акча бүлеп бирелә. Аның 67 миллионы – федераль бюджеттан. Программа нигезендә җәмәгать урыннары, ишегаллары төзекләндереләчәк.

2017 ел өчен, халыкара сезон нәтиҗәләре буенча, Россиянең иң яхшы биатлончылары исемлеге төзелгән. Исемлек башында Чувашия спортчысы Татьяна Акимова тора. Ул барысы 1300 балл җыйган.

ФИФА генераль сәркатибе Фатма Самура «Ведомости» газетасына биргән интервьюсында

Мин Россиянең зурлыгы белән генә түгел, мәдәнияте белән дә сокландым. Иң онытылмас кичерешләрем Казанда булгандыр. Төрле дин кешеләренең үзара гармониядә яшәве, мәчет белән чиркәүне янәшә күрү таң калдырды.

Грипп чигенә

Роспотребнадзор җитәкчесе Анна Попова сүзләренчә, 20 марттан Россиядә тын юллары вируслы инфекциясе һәм грипп белән авыручылар саны 14 процентка арткан.

Татарстанда да авыручылар саны күбәйгән, кош гриппы таралган икән дигән имеш-мимешләр йөри. Роспотребнадзорның Татарстан идарәсе белгечләре хәбәр итүенчә, мониторинг тикшерүләре нәтиҗәсендә, күчмә кош – кыр үрдәкләрендә чынлап та А гриппы ачыкланган булган.

– Бу тикшерүләр белән Новосибирск шәһәрендәге «Вектор» фәнни-тикшеренү институты шөгыльләнә. Әлегә алардан рәсми җавап юк. Шуңа да республикада кош гриппы бар дип әйтеп булмый. 20сеннән 26 мартка кадәр Татарстанда грипп һәм тын юллары вируслы инфекциясе белән 15523 авыручы теркәлгән. Бу күрсәткечләр, узган атна белән чагыштырганда, 5,6 процентка кимрәк, – дип аңлаттылар Роспотребнадзорның Татарстан идарәсендә.

Кыскасы, грипп чигенә.

Социаль пенсияләр арта

1 апрельдән социаль пенсияләр 1,5 процентка – 129 сумга артып, 8774 сумга җитәчәк. Шул күләмдә пенсияләр хәрби хезмәттә булганнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына, Бөек Ватан сугышында катнашканнарга, Ленинград блокадасында яшәгән гражданнарга, радиациягә яки техноген һәлакәтләрдә зыян күрүчеләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына артачак.

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

ТОП – 3

РОССИЯ Дәүләт Думасының «Бердәм Россия» фракциясенең кайбер депутатлары парламент каралышына субъектларда бәби-бокслар урнаштыру кирәкме-юкмы икәнен төбәк хакимиятләренең үзләренә хәл итү мөмкинлеге бирү турындагы закон проектын кертә. Анда Россия субъектларына мөстәкыйль рәвештә мәдәни һәм җирле традицияләрне истә тотып, төбәктә аноним рәвештә бала калдыру урынының ничә булуын һәм кую тәртибен билгеләргә тәкъдим ителә, диелгән аңлатма язуында.

ФРАНЦИЯ хакимияте Эйфель манарасын ядрә үткәрми торган пыяла белән әйләндереп алырга ниятли, дип яза «Татар-информ». Француз хокук сакчылары илдә террор куркынычы гаять зур булуын яшерми. Моннан тыш «пыяла башлык» аны әйләндереп алуга карaганда зәвыклырак булачак, диелә. Манарага пыяла каплагыч ике яктан булачагын һәм туристлар уза торган контроль-үткәрү пунктларына өстәмә тимер рәшәткәләр куелачагы да җиткерелә. Яңалык кертү казнага якынча 20 миллион еврога төшәчәк икән. Әлеге эшләр 2018 ел урталарында төгәлләнер дип көтелә.

БЫЕЛ Татарстан районнарында өч яңа мәктәп төзү ниятләнелә. Якын арада «Салават күпере» микрорайонында мәктәп төзелешенә нигез ташы салыначак. Шулай ук Чаллыда, Арчада берәр мәктәп төзеләчәк. Сүз уңаеннан: Казанның «Җиденче күк» торак комплексындагы һәм «2нче Азино» микрорайонындагы яңа мәктәпләргә балаларны язду 3 апрельдә старт ала. «Җиденче күк» торак комплексындагы мәктәпкә балаларны язду 178нче мәгариф үзәгендә башкарыла. «2нче Азино» микрорайонындагы мәктәпкә балаларны язду эшләре 15нче мәктәптә оештырылачак.

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Равил САБЫР

Сәрхуш нарколог нотыгы

«Чын язучы булсаң, Равил, менә шуны яз син!» – дип берничә кешенең әйткәне бар миңа. Төрлесе төрле тема һәм проблемалар тәкъдим итә, әлбәттә. Берсендә шулай күрше авыл Сабан туена баргач, кызыклы гына бер очрашу булган иде. Бер төркем ирләр (араларында танышларым да бар) машина артына җыелып утырганнар. Яшел чирәмгә зур кызыл чәчәкле җәймә җәеп куйганнар, тәм-томнары да күп, бәйрәм булгач, салырга да бар инде боларның – ничек инде ансыз?!

Мине дә кыстыйлар. «Юк, рәхмәт, – минәйтәм, – мин рульдә бүген». Сөйләшеп киттек. Араларында бер табиб та бар иде – нарколог. Кәефе күтәренке моның, битләре кызарган, сөйли дә сөйли, сөйли дә сөйли…

– Кешенең үз-үзен саклау инстинкты бар бит инде менә, ә бездә аракы түгел, суррогат икәнен белә торып, агу икәнен белә торып, барыбер эчәләр! Нәрсә бу, аңгыралыкмы? Алай димәс идем. Без бит инде авыл малайлары, авыл тормышын бик яхшы беләбез. Менә киләләр инде миңа приемга авыл мужиклары, әйеме, тыңлап утырасың инде аларның сөйләгәннәрен… Билләһи газыйм, үзеңнең дә берәрне салып куясың килә башлый!

Әйтик, алыйк менә тракторист Харисны. Ул, беләсеңме, ничек хоккей уйный иде?! Һи-и-и, кәшәкәсе артыннан күз иярми иде! Катнашкан һәрбер турнирда безнең мәктәп командасы шул бер Харис аркасында гына җиңеп барды! Шул вакытта аны җүнле тренерлар күреп алып талантын үстерергә булышкан булсалар, иманым камил, Зиннәтулла Билалетдинов хәтле генә хоккейчы чыга иде аннан!

Кем арттыра, минме?! Син беләсеңме соң Сергей Бубканы каян тапканнар? Украинаның Алла каргаган бер хуторыннан! Аларның эт оясы хәтле өйләрендә җир идән булган! 11 яшьлек Сергейны интернатка алып китәргә сорап килгәч, әнисе сөенә-сөенә җибәргән, чөнки аңардан башка тагын өч бала ашатасы булган, ә ул – берүзе. Менә сиңа рекордчы, Олимпия чемпионы! 6 метр 14 сантиметр! Һаман рекордын бәрәлмиләр әле, тиз генә булмас та кебек. Ә Харис, Олимпия чемпионы, миллионер буласы урында, тракторист булып йөри. Нишләтәсең, язмыш.

Күптән түгел мин урманга кадәр тракторга утырып барган идем. Бик шәпләп яңгыр яуган иде, гөмбә күпләп чыккандыр инде, минәйтәм, барып кайтыйм әле. Ник утырган көнемә төштем, бүтән якын да килмим дип, антлар эттем! Андагы тавыш, аның сикертүләре! Сүз белән аңлатып бетерерлек түгел! Ә кеше көне-төне шунда эшли, бүтән чарасы булмаганга эшли һәм үлгәнче шушы тракторда утырачагын аңлап эшли. Бушка эшли! Аңа бит хезмәт хакы түләмиләр диярлек! Көне-төне эшләп тә хәерче калган кешеләр җүнле илдә булырга тиеш түгел бит! Мондый тормышының очы-кырыен күрми ул. Бернинди өмете юк аның, ә өметсез – шайтан, ди халык. Аның бер рәхәте дә юк, аңлыйсыңмы? Ә аракы эчкәч, рәхәт булып китә. Җимерек тракторы, дөнья мәшәкатьләре онытыла, ул үзендә шул дөньяны астын өскә әйләндереп атардай көчкуәт бар дип хис итә башлый.

Менә бер кызык эксперимент уздырганнар галимнәр – күселәрне аракы эчәргә өйрәткәннәр. 15 процент чамасы рәхәтләнеп эчә икән дә икенче көнне, берни булмагандай, рәхәтләнеп йөри ди. Тагын 15 проценты баш төзәтергә аракы эзләнә. Калганнары да алдагы көндә эчкәннән чирли, ләкин кичкә тереләчәген белеп түзә икән. Димәк, эзләнеп йөргән күселәр – потенциаль алкоголиклар. Кешеләрдә дә процентлары бүленеш шул чама килеп чыга. Татарларның зур күпчелеге нәкъ әнә шул икенче төркемгә керә, алкоголизмга тиз бирешүчән халык без. Бу авыруга каршы торырга тиешле иммунитет бик зәгыйфь бездә. Моның белән татарлар Төньяк халыкларына охшаган. Алар эчеп кырылып бетеп бара бит инде.

Без бит Бөек Ватан сугышында гына эчәргә өйрәнгән милләт. Революциягә кадәр, татар дип сөйләшүгә караганда, күбрәк мөселман дип сөйләшкәннәр. Ислам дине тәртәдә тоткан халыкны. «Шайтан сидеге» дигән сүз шул вакытлардан калган бит инде. Минем бер танышым бар, филология фәннәре докторы. Ул 1904 елда Казанда чыккан бер урыс гәҗитендә шул чор өчен сенсацион мәкалә укыган. Беренче биткә бастырганнар, моңа кадәр күрелмәгән хәл, дип язганнар! Беләсеңме нәрсә турында? Казан урамыннан бер татар исерек килеш җырлап барган!

Кешене бит аны яхшы гадәткә өйрәтер өчен шактый тир түгәргә кирәк, ә начарын шундук эләктереп алырга гына торалар. Шул исәптән күрше халыктан да. Буддизм белән ислам эчүчелеккә каршы булса, яһүд һәм христиан диннәре исерткеч эчемлекләрне «Ходай Тәгалә бүләге» дип саный. Христиан динен шактый соң кабул иткән Русиядә – әрмәннәр, мәсәлән, берничә йөз ел алданрак кабул иткән – мәҗүсилек ритуаллары шактый сакланып калган. Әйтик, мәҗүсилектә «беренче көн ырымы» булган. Ул хәзер «как встретишь Новый год, так его и проведешь» дигән мәкальдә ачык чагыла. Шуңа күрә бу бәйрәмдә мөмкин кадәр күбрәк ашап һәм эчеп калырга тырышканнар.

Вакыт үткән саен, христиан диненең чикләүләре азайганнан-азая барган, ә эчү белән бәйле йолалар арткаканнан-арткан. Ахыр чиктә барлык бәйрәмнәр вакытында да – туймы ул, бала туумы, шул туган баланы чукындырумы, үлгән кешене күмүме йә булмаса атна саен үткәрелә торган берәр чиркәү бәйрәмеме – һәр мәҗлестә күпләп эчү гадәткә кергән. Кунакларга эчәргә тәкъдим итмәү хурлык булып исәпләнгән, ә үзең эчү һәм башкаларны да шуңа мәҗбүр итә белү егетлеккә санала башлаган. Хәзер инде урыслар гына түгел, без дә, кунаклар килгәндә, өстәлгә шешә чыгарып куюны бурычыбыз итеп санныйбыз.

Шунысы бар: безнең татар мужиклары, бүтәннәрдән аермалы буларак, ничек дип әйтим икән, алар… Ничектер ояла алар, эчеп ярамаган эш эшләгәннәрен аңлыйлар. Минемчә, без ул кадәр үк өметсез түгел. Милләтнең үз-үзен саклау инстинкты берзаман барыбер уяныга тиеш бит.

***

Әллә ничә ел элек булган бу очрашу нидән искә төште, дисәгез, күптән түгел бу нарколог турында күңелсез хәбәр ишеттем. Эшеннән куганнар икән. Эчкечелек өчен…

Автор фотосы

Укысаң – алданмассың

Торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләргә, түләү кәгазьләрендәге бәяләргә ризасызлык белдереп, хакимият һәм хокук саклау органнарына хатлар язучыларны яратып бетермибез. Картайган инде, саран кеше, дибез.

Ашыкмыйча уйлансак, шушы берән-сәрән активистлар без «наданнарны» алдаулардан коткарырга тырышып йөри бит.

– Халыкның 70 проценты торак-коммуналь хезмәтләр өчен, ничек язып китерелгән булса, шулай түли. Ләкин Татарстандагы кайбер идарәче компанияләр исәп-хисаплар ясауда алдаша, – дигән фикердә тора Россия Дәүләт Думасы депутаты Александр Сидякин.

«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында үткәрелгән матбугат конференциясендә сөйләгәннәренә караганда, Татарстанда билгеләнелгән торак-коммуналь нормативлар бик түбән. Россия төбәкләре арасында безнең нормативлар күрсәткече исемлектә – ахырдан унынчы. Әмма түбән яки аз нормативны «яхшы» дип аңларга кирәкми икән. Мәсәлән, шәһәрләрдә кеше башына су, электр уты нормативлары билгеләнә. Моны, депутат әйткәнчә, Мәскәү түгел, ә төбәкләр үзләре билгели.

– Гомумйорт чыганакларыннан (ОДН) һәркем файдалана. Болар: подъезддагы ут, лифт, баскычларны юу һәм яшеллеккә сиптерү өчен су, елына бер мәртәбә опрессовка һәм торбалардагы суны кире агызу, – дип аңлата Александр Сидякин. – Тик ишекләрдәге магнитлар, кайбер кешеләрнең үз фатирларындагы хисаплагыч приборларны бозулары, ягъни төрле ысуллар ярдәмендә күрсәткечләрне киметүләре, күпкатлы йорт милкен урлашулар, хисаплагыч приборлары булмаган фатирлардагы нормадан тыш кулланылган чыгымнар, йорттагы чыганакларга ялганган чит оешмалар – һәммәсе ОДН булып языла. Кеше күпкатлы йортның чормасына менеп яки подвалына төшеп, гомерендә дә электр уты кабызмый, әмма бу да ОДН итеп языла. Фатирдагы хисаплагычлар белән гомумйорт хисаплагычлардагы аерманы ОДН диләр. Бу – ОДН түгел, ә идарәче компанияләрнең балансска сыешмавы. Моны торак милекчеләре өстенә аудару дөрес түгел, нормативларга сыешмаган, ягъни балансстан узып киткән чыгымнарны каплау – идарәче компанияләрнең үз мәсьәләсе.

Александр Сидякин ялган беркетмәләр тутыручы идарәче компанияләргә карата җинаять эше кузгату темасын Россия Дәүләт Думасында күтәрәчәген искәртте.

Казанның Лобачевский урамындагы 10в йортка урнашкан «Төбәк җәмәгатьчелек контроле үзәге» апрель аенда «Белемле кулланучы мәктәбе»нең чираттагы бушлай курсларын башлый. Аңа **8(843) 236-29-97** телефоны аша язылырга мөмкин. Шалтыратулар дүшәмбе-җомга көннәрендә 9.00-18.00 сәгатьләрдә кабул ителә.

Дамир БӘДРИЕВ.

Мәчет каршында җеназаханә

Кинәт кенә вафат булган кешенең якыны бер мизгелгә югалып, каушап кала. Янәшәсендә киңәшләшерлек кешесе дә булмаска мөмкин. Мәетне соңгы юлга озату хәстәрен нәрсәдән башларга, аның алдындагы дини вазифаларны ничек дөрес үтәп чыгарга, моның турында яхшы белгән кешене каян табарга?

Башкаланың «Казан нуры» мәчете, шуларны истә тотып, мәрхүм булган мөселман кешене шәригатькә туры китереп юып, кәфенләп, җеназа укып озатуны үз эченә алган хезмәт булдырган. Җеназаханәне арендага алу – 2000 сум.

– Мәчет каршында эшләп килүче җеназаханә турында әлегә күпләр белми, – диде безгә «Казан нуры» мәчете имам хатибы Наил хәзрәт Кәримуллин. – Җеназаханә ачу уе белән мәчетнең имамы булган мәрхүм Шамил абый Исхаков та йөргән иде. Ул вакытта бу эш ничектер барып чыкмады. Улы Камил Исхаков инициативасы белән, узган ел ахырында без аны ачтык та. Шәһәр шартларында җеназаны Аллаһ хозурына озату мәшәкате күбрәк. Шуңа да без җеназаханәне кешеләргә уңайлы булсын өчен булдырдык. Биредә мәетне юарга бөтен мөмкинлекләр дә бар, теләсәләр, үзләре дә юа ала, кирәк икән, мәетне юучыларбыз да бар. Кәфенлекләр дә бирәбез, аны хәстәрләп өлгермәүчеләргә дә җайлы бу.

Мондый хезмәт моргларда да бар, диючеләр табылыр. Наил хәзрәтнең моңа да үз җавабы.

– Мәет юарга моргка үземнән дә баргаганым бар. Анда хатын-кызны ир-ат юа, икеөч өстәлдә берьюлы берничә кешене юалар. Дини таләпләр буенча, мәетне юуның үз кагыйдәләре бар. Аллаһ каршына ул госелле килеш барырга тиеш. Аны юучыларның да тәһарәтле булуы шарт. Монда исә мәетне соңгы юлга озату бөтен шартларына туры китереп эшләнә. Киләчәктә мәетне зиратка алып бару өчен махсус автобус булдыру уе да бар, – диде ул безгә.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Сәхифәбезнең киләсе темасы инвалидлык алу тәртипләренә кагылачак. Сорауларыгызны **8 (843) 562-50-12, 562- 50- 03** телефоннары аша редакциягә юллый аласыз.

Социаль ипотека: ничек, кайчан?

2005 елдан 2016 елга кадәр республикада социаль ипотека программасы буенча барлыгы 118 мең гаилә тораклы булган. Бу өлкәдәге үзгәрешләр турында гел язып торсак та, программадагы яңалыкларны халыкка җентекләп аңлатсак та, социаль ипотекага кагылышлы сораулар редакциябезгә еш килә. Бу юлы укучыларыбыздан килгән сорауларга Татарстан Президенты каршындагы Торак фондының мәгълүмат сәясәте төркеме җитәкчесе Лилия Маннапова җавап бирә.

Эльвира **МОЗАФФАР**

– Социаль ипотека программасына элэгү өчен ничә ел бюджет өлкәсендә эшләргә кирәк?

Динара ХӘЙРЕТДИНОВА, Казан.

– Социаль ипотека программасы буенча чиратка басар өчен документлар тапшырганда, бюджет өлкәсендәге стаж роль уйнамый.

– Социаль ипотека программасы буенча фатир алырга чиратта торам. Фатирлар уйнатылган очракта, конкурста катнашу өчен нинди шартлар үтәлгән булырга тиеш? Исәп счетында мин сайларга теләгән фатир бәясенең ун проценты булмаса, конкурста катнашып булмый диган сүзләр дөресме?

Алинә ГАРИФУЛЛИНА, Яшел Үзән районы.

– Фатирлар уйнатылачак конкурста социаль ипотека килешүен төзегән барлык гражданнар да катнаша ала. Бюджет өлкәсендә эшләүчеләр өчен сайларга теләгән фатир бәясенең кимендә ун проценты исәп счетына беренчел кертем итеп салынган булуы шарт. Торак фонды белән килешү имзалаганнан соң, исәп счетына ай саен даими рәвештә билгеле бер күләмдә кертемнәр түләп барырга туры киләчәк. Гадәттә, шул кертемнәр өч ел эчендә сайланачак фатир бәясенең 10 проценты күләмендә җыела да. Шул рәвешле, сез өч елдан соң, айлык кертемнәр түләп тә конкурста катнашу хокукы алырга мөмкинсез.

– Без социаль ипотека буенча алынган фатирыбызны, «обременение» шарты белән, милкебез итеп рәсмиләштердек. Гаиләдә бала туган очракта, кредитның бер өлешен дәүләт бала өчен бирә торган ташлама белән капларга буламы?

Роза ГАДЕЛШИНА, Казан.

– Займ, ягъни мәсәлән, бурычка акча алу милеккә ия булу хокукын бирә. Максатчан акча займы килешүе төзегән, социаль ипотека программасы буенча алган фатирларын фонд файдасына «обременение» шарты белән рәсмиләштергән гаиләләргә, бала туган очракта, дәүләттән 200 мең сум акча бирелә. «Обременение» вакытында йорт милек итеп рәсмиләштерелсә дә, аның бәясе тулысынча түләнеп бетмичә, торакны сату, алыштыру рөхсәт ителми. Шуны да истә тотарга кирәк, социаль ипотека программасы буенча фатир алганда, гаиләдә бала туган очракта каралган 200 меңне исәп счетына күчерү өчен, аны социаль ипотека килешүенә кертергә, баланың фатирда өлешен билгеләргә кирәк.

– Торак шәһәр үзәгеннән бик ерак урнашу сәбәпле, аннан фатир алырга теләмибез. Әгәр өч ел узганнан соң да фатир сайламасак, безне программадан төшереп калдырачакларымы?

Вәлиуллиннар гаиләсе, Казан.

– Әгәр дә сез өч ел узгач та конкурста катнашмагансыз, фатирлар сайламагансыз икән, Татарстан Министрлар кабинетының нигезләмәсе буенча (№847, 12.10.2011 елдан), чират буенча фатир оту хокукыннан мәхрүм ителәсез. Дөрес, бу – программадан төшеп каласыз диган сүз түгел. Бары тик чират буенча фатирлар отылып беткәннән соң торак калган очракта гына, конкурста катнаша аласыз.

– Предприятиедә эшләүчеләрнең фатирлар уйнатуда катнашканда беренче кертемнәре ничә сум булырга тиеш?

Айрат САФИУЛЛИН, Казан.

– Предприятие хезмәткәрләре исәп счетына беренчел кертемне сайланачак фатирларының кимендә 20 проценты күләмендә салырга тиеш. Предприятие хезмәткәрләренә булачак фатирның нормативын буш квоталар кысаларында Торак фондына акча күчерүче оешма үзе билгели.

– Ана капиталын фатир кредитын түләү өчен файдаланган идек. Ул чакта социаль ипотека буенча алынган торагыбызны Теркәү палатасы аша үз милкебез итеп рәсмиләштердек. Тиздән фатир өчен кредитны түләп бетерәбез. Безгә кабат Теркәү палатасына барырга туры киләчәкме?

Гыйсмәтуллиннар гаиләсе, Казан.

– Юк, сезгә Фондның төбәкара вәкиллегенә барып, займ килешүе буенча, бурычны тулысынча түләп бетерү турында тикшерү (сверка) акты алырга кирәк. Аннары «обременение»дән төшү өчен бернинчә көн алдан Татарстан буенча күп функцияле үзәктәге белгечләргә язылырга туры киләчәк.

Моны www.uslugi.tatarstan.ru сайтында хокукны теркәү бүлеге аша да эшләргә була яки 8-800-100-34-34 телефоны аша белгечкә языласың. Күп функцияле үзәктә кабул итүләр бары айның сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә генә башкарыла. Шулай ук бары 14.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр генә «обременение»не төшерергә мөмкин. Кабул итү бүлмәсенә язылганнан соң, Төбәкара вәкиллеккә кайсы көнгә, сәгать ничәгә язылуыгыз турында хәбәр итүегез мәҗбүри. Шулай ук бирелгән талон номерын да әйтергә кирәк (ул гадәттә, ПР хәрефләре белән башлана). Әгәр язылган көнгә бара алмыйсыз икән, бу хакта шулай ук төбәкара вәкиллеге җитәкчесен кисәтергә кирәк. Язылган көнгә күп функцияле үзәккә паспорты булган барлык гаилә әгъзаларына да килергә кирәк. Гаиләдә балигъ булмаган балалар булса, аларның туу турындагы таныклыкларының төп нөсхәсен алып килү мәҗбүри. Шулай ук Төбәкара вәкиллектән алынган тикшерү актының оригиналын, күчерелмәсен һәм пай түләве турындагы белешмәнең нөсхәсен алып килү сорала. Төбәкара вәкиллектән килгән белгеч тә фатирдан «обременение»не төшерү процессында катнашачак.

– Социаль ипотека программасы буенча чиратта торучылар исәп счетына ай саен ничә сум акча күчереп барырга тиеш?

Алия ВАФИНА, Яшел Үзән.

– Татарстан Президенты каршындагы дәүләт торак фонды коммерциячел булмаган оешма белән социаль ипотека килешүе имзалаганнан соң, ай саен исәп счетына билгеле бер күләмдә акча күчереп бару сорала. Бу торак базарында бер квадрат метрның уртача бәясеннән чыгып исәпләнә. Исәп счетына салынасы акча шул 1 квадрат метрның 11 процентыннан да кимрәк булмаска тиеш. Базардагы 1 квадрат метр торак бәясе төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча федераль агентлык тарафыннан билгеләнә. Хәзерге вакытта бу сумма 3843,29 сумны тәшкил итә.

– Әни белән социаль ипотека программасы буенча алынган фатирда яши идек. Мин өйләндем, хәзер хатыным авырлы. Әмма ул безнең фатирда теркәлмәгән. Бала өчен 200 мең сум күчсен өчен нишләргә була? Гомумән, бу мөмкинме?

Альберт САДЫЙКОВ, Казан.

– Әгәр дә баланың әтиәнисенең берсе булса да социаль ипотека программасына кертелгән булса, 200 мең сум компенсациягә өмет итәргә була. Дөрес, ул дәүләт ярдәме акчалата бирелми, аны банктагы исәп счетына да күчереп булмый. Бары торак буенча кредит суммасын киметү өчен генә файдаланырга мөмкин.

– Кеше бер тапкыр социаль ипотека программасы буенча фатир алса, ул торак шартларын яхшырту өчен кабат программа буенча чиратка баса аламы?

Фәизовлар гаиләсе, Чаллы.

– «Министрлар кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү» турындагы Министрлар кабинеты карары нигезендә, (16.09.2013г. №659) фатирга дәгъва кылучы гаилә социаль ипотека программасы буенча бары бер генә тапкыр фатир алырга хокуклы. Дөрес, искәрмәләр бар: гаилә 2013 елның 1 октябренә социаль ипотека программасы буенча кабат торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип табылса яки гариза тапшыручы социаль ипотека программасын финанслаучы предприятие хезмәткәре булып саналганда, программа буенча икенче тапкыр да фатир алырга дәгъва кыла ала.

– Укытучыларга социаль ипотека программасы буенча торак алганда өстәмә ташламалар каралган. Укытучылар гаиләсе фатирны 2010 елда алган. Әмма аларга бернинди дә ташлама ясарга теләмиләр, ди. Нигә икән?

Инсаф ЯРУЛЛИН, Яшел Үзән.

– Бер ел эш тәҗрибәсе булган, яше 35 яшьтән артмаган яшь укытучыларга социаль ипотека программасы белән фатир алганда чынлап та ташламалар каралган. Мәгариф һәм фән министрлыгы фатир бәясенең ун процентын күчерә. Әмма бу 2012 елның 1 гыйнварыннан соң фатир алучыларга гына кагыла.

– Социаль ипотека буенча алынган фатир бәясен түләп бетергәннән соң кая мөрәҗәгать итәргә?

Зәмирә БИКБАЕВА, Казан.

– Социаль ипотека буенча пай түләүләрен түләп бетергәннән соң, программа буенча килешүдәге 14 яшьтән зуррак булган гражданнарга Торак фондының төбәкара вәкиллегеннән пай түләнү турында белешмә алырга кирәк. Үзең белән паспорт, ИНН, займ килешүен алып килү сорала. Әлеге документ фатирны үз милкең итеп рәсмиләштерергә ярдәм итәчәк.

ҮЗЕМ КҮРДЕМ

АШЫГЫЧ ЯРДӘМ

«ШК» журналисты ашыгыч ярдәм хезмәтенең эшчәнлеге белән якынрак танышу өчен, Казан шәһәренең 1нче ашыгыч медицина ярдәме хезмәте станциясенә юл тотты.

Эльвира МОЗАФФАР

24 СӘГАТЬЛЕК ЭШ

Сәгать кичке унбер. Станциядә көн башланган гына диярсең. Хәер, монда эш сәгатен көнгә, төнгә аеру юк. Хезмәткәрләр тәүлек буе эшли. 14нче бригададан ирле–хатынлы фельдшерлар Илнур Миңнуллин белән Алинә Камалова да иртәнге сәгать җидедән бирле аяк өстендә. 24 сәгать эшләгәннән соң гына сменаларын тапшырачаклар. Төнгә каршы шактый талчыксалар да, сер бирмиләр. Шаярткан булалар. «Өйдә дә бар сөйләшкәнебез – медицина темасы», – диләр.

Чакыру килгәнне көткән арада, станция турында сорашам. Казан буенча тугыз Ашыгыч ярдәм станциясе исәпләнә икән. Халыкка барлыгы 80 бригада хезмәт күрсәтә. Араларында балалар, психик авырулар, йөрәк–кан тамыр хастәлекле авырулар өчен махсуслашканнары да бар. 1нче подстанция хезмәткәрләре Вахитов, Совет, өлешчә Идел буе районнарыннан кабул ителгән чакыруларга бара. Территориаль бүленеш авыру янына тиз арада барып җитү өчен уйланылган. Шалтыратуларны кабул итүче белгечләр, сораулар биреп, авыруның хәле ни дәрәҗәдә икәнне билгеләрләр. Бик кискен очракларда: кеше гомерена куркыныч янаганда, бәла–каза булганда, янгын, юл һәлакәтләре урынына беренче чиратта ашыгалар. Шулай ук бер яшькә кадәр сабыйлар, аңын югалтканнар, тулгагы башланган авырлы хатыннар, йөрәк–кан тамырлары авырулары кузгалган кешеләр янына да ким дигәндә 20 минутта килеп җитәргә тырышалар. Чакыруга гадәттә табиб белән фельдшер йә ике фельдшер бара.

Шул арада чакыру кабул ителде. Космонавтлар урамында 51 яшьлек ханымның кан басымы күтәрелгән. Ике минут дигәндә җыенып, авыру янына кузгалдык. Төнге юл шомландырса да, уңай ягы бар – юлларда бөкеләр юк. Биш минут дигәндә, тиешле урынга килеп тә җиттек. Дөрес, көндез төрле чаклар була икән.

– Ярый, соңгы вакытта ЮХИДИ хезмәткәрләре белән уртак эш алып барыла башлагач, ашыгыч ярдәм хезмәте машиналарына юл бирә башладылар. Бик кискен очракларда, сирена кабызып, тизлекне арттырырга, светофорның кызыл утына да кереп китәргә туры килә, – ди шофер Михаил Репеев.

Аны фельдшерлар, үз итеп, «Миша дәдәй» дип йөртә. Ул – табибларның уң кулы. Караңгыда кирәкле адресны эзләү уңайсыз, көндез дә тиешле торакны табуы бер бәла. Йортка номерлар сугылмаган, урамнар күрсәтелмәгән. Ә Миша дәдәй районны биш бармагы кебек белә.

– 30 ел эшләү дәверендә, һәр ташның кайда ятканын әйтеп бирә алам инде, – дип көлә үзе.

Тиешле адресны тиз эзләп тапсак та, фатирга кергәнче, вакыт узды. Машина подъезд төбенә кадәр үк керә алмый, ишегалды автомобильләр белән тулган, җәяү тәпиләргә туры килде. Һәр йорт ишегалдында диярлек шундый хәл. Авыруны носилкалар белән күтәреп чыгарга туры килгәндә, бигрәк тә уңайсыз.

Ишекне кан басымы күтәрелгән хатынның ире ачты. Борчылуы йөзенә чыккан. Хатын, мәчесенең эчендәге суалчаннарны бетерер өчен, даруханәдән препарат алган. Тик мәчесен генә дәвалап калмаган, профилактика чарасы булыр дип, үзе дә бу даруны эчкән. Нәтиҗәдә хәле начарланган, кан басымы 220дән артып киткән. Фельдшерларны күргәч, йөзенә елмаю кунды.

– Сез минем улыма охшагансыз. Рәхмәт инде сезгә. Хәлем дә җиңеләйде сыман, – диде, Илнурга төбәлеп.

Үзе бертуктамый ирен кузәтә. Иренә ара–тирә күз дә кыскалап ала. Баксаң, йөрәгә авырткан ирен борчымас өчен, хатынның үз хәле хәл булса да, сиздермәскә тырышуы икән. Алинә кардиограмма төшерде, Илнур кан басымын үлчәде. Авыруга тиешле укол кададылар, дарулар бирделәр. Хастаханәгә илтергә дә теләгәннәр иде дә, ханым ризалашмады. Фельдшерлар алдагы сәгатьләрдә нишләргә кирәклеге турында киңәшләр биреп, участок табибына барырга, тикшеренергә куштылар. Ханымның боздай салкын кулларына җылы йөгерде, ул дөнья хәлләре, берәүнең миллион сум отуы турында сөйли башлады. Без исә, җиңел сулап, юлыбызны дәвам иттек.

– Кан басымы югары булганда, кешенең күңеле болганырга, башы авыртырга, хәле авыраерга тиеш. Организм үзгәрешләрне тоймый икән, бу дөрес түгел, еш кына шул рәвешле кеше инсульт булганны да сизми кала. Шуңа да олы яшьтәгеләргә кан басымын даими үлчәп торырга кирәк, – ди ашыгыч ярдәм хезмәтендә тугызынчы елын эшләүче Илнур.

Программист булырга хыялланса да, язмыш аны медицина өлкәсенә китергән.

– Бирегә килгәннәрнең, гадәттә, унысыннан дүртесе генә эшләп кала. Ә кала икән, димәк, озакка. Бары һөнәреңне яратсаң гына эшләп була монда. Иң мөһиме – җаваплылык, түземлелек, авыруны аңлый белү, тәҗрибә кирәк, – ди Илнур.

Аның ашыгыч ярдәм хезмәте машинасында бала таптырганы, авыруның соңгы сулыш алганын күргән чаклары да булган. Җәй көне чакыруларга Ашыгыч медицина ярдәме станциясенә кайтартылган махсус мотобайкларда да чыга икән.

– Казанның тар урамнарына керү өчен мотоцикллар җайлы, вакыт ягыннан да тиешле урынга тизрәк килеп җитәсең, – ди Илнур Миңнуллин.

ТАЙДЫМ. ЕГЫЛДЫМ. ГИПС

Алинәнең фельдшер булып эшли башлавына бер еллап кына икән.

– Шөкер, бүген медицина модернизацияләнә. Ашыгыч ярдәм машиналарында барлык уңайлыклар да тудырылган, кирәкле җайланмалар бар. Эш җиңел түгел. Шулай да тәҗрибә туплар өчен нәкъ менә ашыгыч ярдәм хезмәтендә эшләү файдалы. Төрле авырулар белән очрашасың. Илнур янәшәдә булганда, үземне ышанычлы тоям. Төнге сменаларда нинди очраклар гына булмый. Исерекләр, сугышкан яшьләр... Андый урыннарга полиция хезмәткәрләре дә чакыртыла анысы, шулай да янәшәңдә ышанычлы терәк булганда яхшырак, – ди фельдшер Алинә.

Машинага чыгып җитәргә дә өлгермәдек, тагын бер чакыру. 74 яшьлек бабай кулын сындырган. Фатирга килеп керүгә, спирт исе борынга бәрде. Әллә йокыдан исергәннәр, әллә бәйрәм шаукымы – бабайның кызы да, әбисе дә, үзе дә чайкалып–чайкалып китәләр. Бабай кулын атна башында ук сындырган булган. Хастаханәдә гипс салып җибәргәннәр. Хәзер менә тагын шул кулына егылган. «Аш бүлмәсенә генә чыккан идем, таеп киттем», – ди. Югыйсә, әле бер ай элек кенә югары уку йортында студентлар укытып йөргән. Моңа кадәр егылганы булмаган. Бабайны киендереп, хастаханәгә алып киттек. Кызы озата барды. Иңбашы, терсәге чәрдәкләнеп сынса да, бабай сиздерми. Авыруның көче нәкъ менә түземле булудадыр, мөгаен. «Авыртмый», – дигән була. Кызы исә рәхмәтен җиткерергә ашыга.

– Сезнең кебек табибларны күргән юк иде әле. Рәхәт сезнең белән. Тынычланып китәсең, – ди.

7нче шәһәр хастаханәсендә кизү торучы табиблар алып калды бабайны. Чакырулар минут саен. Табиблар махсус планшет, рация, кесә телефоны аша да кабул итә аларны. Бер станциягә тәүлегенә якынча 1400ләп шалтырату килә. Кайвакыт бригада хезмәткәрләренең бәдрәфкә барырга да вакытлары калмый. Буш вакытларында сумкаларындагы кирәкле медикаментларны барлыйлар. Ашар өчен вакыт каралган анысы, хәтта үзләренең уңайлы гына ашханәләре дә бар. Тик чакыру була икән, ашау кайгысы калмый. Барын да калдырып, ашыгырга туры килә. Төнлә йөрәк–кан тамыры авырулылардан чакырулар күбәя. Сәгать 18.00дән 22.00гә кадәр юл һәлакәтләре еш була. Ял көннәрендә клубларда, барларда сугышалар, исерекләр күп. Аларны, тән җәрәхәтләре булмаса, әле бер ай элек кенә ачылган айныткычка илтәләр. Кайвакыт, бармагы киселгәнгә ашыгыч медицина ярдәме чакыртучылар да бар. Ялгызлыктан интеккән карт–карчыклар да гел шалтырата. Һәр чакыру буенча бригада диспетчерга хисап рәвешендә язмача аңлатма тапшыра.

Вакыт узганы сизелми дә. Тимрәү иярткән әби, барда сугышкан бер исерек янына барып кайткан арада, сәгать өч булган. Иртә белән эшкә барасын уйлап, кайтырга кузгалам...

АШЫГЫЧ ЯРДӘМ ХЕЗМӘТЕН НИЧЕК ЧАКЫРТЫРГА?

✓ Ашыгыч ярдәм хезмәтен **03**, кесә телефоны аша **103** һәм **112** телефоны аша чакыртырга була. Ишетмәүче, сөйләшү белән проблемалары булганнар кесә телефоныннан **+7–987–297–41–36** номерына, чакыртуның сәбәбен аңлатып, смс хәбәр юллый ала. Медицина ярдәмен чакыртучы фельдшерның сорауларына анык җавап бирергә тиеш.

✓ Чакыртуның сәбәбен, авыруның исем–фамилиясен, яшен, адресын (урам исемен, йорт, фатир, подъезд номерын, хәбәрләшү өчен телефон номерын) төгәл әйтергә кирәк. Гадәттә, фельдшер ахырдан сез биргән мәгълүматны кабатлап чыга. «Сезнең чакыру кабул ителде», – дип, медицина хезмәте килгәнне көтәргә куша.

«Яхшыга өметләнгән идек, әмма...»

яки авыл хуҗалыгы тармагы бүген нинди авырлык кичерә?

Язгы кыр эшләренә керешергә бер айдан да кимрәк вакыт калып бара. Шуңа күрә авыл хуҗалыгы тармагына мөнәсәбәте булган һәр кешенең телендә дә, башында да менә шушы тема.

АКТУАЛЬ ТЕМА

krestianin.ru

Зөһрә САДЫЙКОВА

Моңа кадәр җитәкчеләр, әзерлек мәсьәләсендә берникадәр проблемалар булса да, гомуми хәл яхшы, дип белдереп килде. Әмма шушы көннәрдә телдән төшмәгән тагын бер мәсьәлә баш калкытты. Аграрийлар өчен гаять җаваплы вакытта Россия хөкүмәте аларга биш процентлы ташламалы кредитлар алу мөмкинлеген бирде. Эш шунда ки, быелдан кыр эшләренә ташламалы кредит алу схемасы бөтенләй башка төрле. Алдагы елларда хуҗалык югары процент белән кредит алып, соңрак аның субсидиясен Авыл хуҗалыгы министрлыгы аша кайтара иде. Моның өчен кредит алучыга компенсацияне алыр өчен акчаларның максатчан тотылуын раслаган хисаплар һәм башка төр документлар тапшырырга туры килде. Быел исә Авыл хуҗалыгы министрлыгы кредит алу схемасында катнашмый. Клиент биш процентлы кредитны турыдан-туры банктан ала. Моның нәрсәсе начар соң, диярсез? Дөрестән дә, бар да яхшы кебек, әмма Татарстан ситуациянең киеренке хәлдә булуы турында әйтә. Кредит алу ресурслары арттырылуга, юллары да җиңеләйтелүгә карамастан, кредит алу чагыштырмача авырлык белән бара. Сәбәп нидә соң? Беренчедән, әлеге программа бик соң гамәлгә ашырыла башлады, икенчедән, урау юллар кыскартылса да, документлар җыю, кредит алу шартлары катлауландырылган.

– Бүгенге кебек хәлгә калмас өчен, Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы хөкүмәт белән алдан килешеп, яңа системаны пилот рәвешендә берничә төбәктә эшләп карарга тиеш иде. Шул ук вакытта кредит алуның элеккеге тәртибен дә калдырырга кирәк иде. Ә безнең алай килеп чыкмады. Дөрестән дә, бу эшне камилләштерү буенча сөйләшүләр узган елдан ук барды, әмма алар (Россия хөкүмәте. – **З.С.**) кырт кистеләр һәм сайлау мөмкинлеге калдырмадылар. Банк кредит бирүне хуплаган очракта, әлеге килешү төп офисына юлланыла, аннан Россиянең Авыл хуҗалыгы министрлыгына китә. Шуннан соң ул карый һәм яки хуплый, яки кире кага, аннан гына банк кредит бирә. Әлеге эш ике-өч атнага кадәр сузылачак. Бу, әлбәттә, катлаулы. Ә без, борын төбендә – чәчү, дибез. Бер ияләнербез анысы. Аннан соң, киресенчә, уңайлырак та булыр, әмма әлегә хәлләр катлаулы, – дип белдерде «Бердәм Россия» партия лигасының утырышында Татарстан премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов.

Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Хәйруллин фикеренчә, ташламалы кредит буенча авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә федераль банкларга караганда, төбәктәгеләр белән эшләү күпкә уңайлырак.

– Безнең максат – кредит алу схемасын җиңеләйтү иде. Нәтиҗәдә проблемалар гына артты. Кече һәм урта банклар үз клиентларын танып белә, ике арада ышанычлы мөнәсәбәтләр урнашкан иде. Әмма быелдан кредит бирүнең яңа системасы кертелгәнлектән, 20 млрд капиталы булмаган фермерлар ярык тагарак алдында калды. Безнең икътисадка кече банклар кирәк, чөнки алар документлар тапшыруның җиңел юллары буенча эшли. Шуңа күрә Мәскәүгә урыннардан үтенечләр җиткерелергә тиеш. Кече авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре эре банкларның ишеген ачып керә алмый. Шунлыктан әлеге программага озак еллар безнең фермерларга ярдәм итеп килгән банкларны кертергә кирәк,– дип саный Айрат Хәйруллин.

Фермерларга субсидияле кредит бирү өчен банклар Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгында аккредитация узарга тиеш. Министр әйтүенчә, Татарстанда мондый аккредитацияне «Ак Барс Банк» кына алган.

– Дөрес, килешүгә кул куюны әлегә кадәр сузалар. Мин идарә рәисеннән әлеге мәсьәләне тизләтүен сорадым, чөнки безнең төбәк банклары белән эшләргә ияләшкән клиентлар бар. Шул исәптән «Энергобанк» ел саен язгы чәчү чорында өч млрд сум кредит бирә иде, ә быел ул ташламалы кредитта катнашмый. Чаллыдагы «Акибанк» белән дә шундый ук хәл, – ди министр.

Министр әйтүенчә, язгы кыр эшләре өчен 20 млрд сум акча кирәк, моннан кала җәйге сезонга өстәмә 27 млрд сум таләп ителә. Быел аграрийлар 10 млрд сум кредит алырга өметләнгән булган. Әмма килеп чыккан кыенлыклар аркасында, татарстанлылар әлегә 4,5 млрд сум кредит кына ала алган.

Татарстан фермерлары һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе башлыгы Камияр Байтимеров әйтүенчә, Татарстанның 4700 фермер хуҗалыгының нибары тугызы гына ташламалы кредит программасыннан файдаланган. Шуңа күрә сайлап алынмаган акчалар башка төбәкләргә китмәсен өчен, хәзерге вакытта крестьян-фермер хуҗалыклары белән аңлату эшләре алып барыла.

Сөйләшү барышында «Татфондбанк»тан зыян күргән фермерлар турында да телгә алынды. Марат Әхмәтов әйтүенчә, әлеге банкта республика авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең 300 млн сум акчасы калган.

– Әлеге акчаларны фермерларга беркем дә үз ихтыяры белән китереп бирмәячәк. Президентның биш млн сумга кадәр биш процентлы займ турындагы карары бар, без бу вариантны барлык зыян күрүчеләргә дә җиткердек, тик әлегә мондый займны дүрт кеше генә алды, – диде министр.

ТАТАРСТАН КӨНДӘШЛЕККӘ СӘЛӘТЛЕМЕ?

Җитештерелгән продукциянең кибет киштәләрендә сатылуы да кирәк бит әле. Татарстан Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану агросәнәгать сәясәте комитеты рәисе Таһир Һадиев әйтүенчә, 2015 ел белән чагыштырганда, бәяләр әллә ни артмаган. Ипи – 11-12 процентка, бераз ак майга, кара чәйгә күтәрелгән, ә кайбер продуктларның бәяләре хәтта кимегән дә әле. Депутат супермаркет киштәләрендә Татарстан азык-төлекләренең аз булуы турында борчылуын әйтте.

– Сәүдә сатып алынган продукциянең бәясе арзанаю хисабына эшли. Әлегә җитештерүче оттыра. Узган ел Татарстанда үстерелгән кыяр кибеттә нибары 28 процент булса, быелның 1 гыйнварыннан – 10 процентка, помидор 7,5 проценттан 5 процентка калган, ә алма һәм кишер бөтенләй юк, – ди Таһир Һадиев.

Әмма Марат Әхмәтов, аңа карап кына, үстергән яшелчәсен җитештерүче сата алмый, дигән сүз түгел, дип каршы чыкты. Аның өчен иң мөһиме – товарны файдага сату, ә бу эш кибетләр аша гына башкарылмаска да мөмкин.

– «Майский» үз продукциясен бик яхшы сата бит! Аннан соң, мәсәлән, шул ук кишерне кибет киштәсендә сату өчен күп акча кертергә кирәк. Уңышлы көндәшлек булсын өчен, Татарстан компанияләренә модернизациягә 27 млрд сум акча таләп ителә. Көнчыгыш илләре үз фермерларына һәр гектар өчен 25 мең акча бирә, аларның ашлама, орлык, ягулык, саклау чараларын каян алыйк икән дип башлары авыртмый. Ә бездә мондый ярдәм – гектарына 1,5 мең. Әлеге шартларда ничек көндәшлеккә сәләтле булып була? – дип гаҗәпләнү катыш ачына Марат Әхмәтов.

АВЫЛ ХАЛКЫНЫҢ ХЕЗМӘТ ХАКЫН КҮТӘРИК!

Шулай да кредит алу мәсьәләсендә хәлләр ничек кенә киеренке булса да, язгы кыр эшләрен лаеклы башлап җибәрү өчен финанслар да, башка ресурслар да җитәрлек, дип белдерә министр. Ә киләчәктә алыначак кредитлар алдагы эш этапларында файдаланылачак, дип планлаштырыла.

Саннар, ресурслар, кредитлар... Ә болар артында гап-гади җир кешесе, иртә таңнан торып җирдә бил бөккән, җиде кат маңгай тирен түккән авыл кешесе тора. Шуңа да, бәлки, әлеге сөйләшүдә дә сүз очы үзеннән-үзе аңа барып ялганды. Язманы да Айрат Хәйруллинның фәлсәфи фикерләре белән тәмамлыйсы килә.

– Авыл хуҗалыгы бүген нефть чыгаруга караганда да керемлерәк. Бары тик бу турыда бик азлар, безнең илдә иң аз хезмәт хакы алучы авыл халкы гына белә. Без кибетләргә яхшы бәядән сыйфатлы продукция куелуын телибез, тик тиешле ярдәм дә булырга тиеш! Аллага шөкер, республика җитәкчесе халыктан аерылмаган һәм хәлне дә аңлый, әмма безгә әле бик күп эшлисе бар. Һәм моны Мәскәүдә эшләү бик авыр. Хөкүмәт еш кына халыктан аерыла. Әйдәгез, авыл халкы шәһәр кешесенә караганда да күбрәк хезмәт хакы алырлык итеп эшлик! Балаларны туган нигезендә башкача ничек тотып калырга? «Улым, син кал һәм ике тапкыр азрак булган хезмәт хакына куанып яшә», – дияргәме?..– ди депутат.

МИЛЛИ ЙОРТ

Кунак көе, кунак сые

Дусларым шалтыратты. Себергә китеп барышлары икән, бер поездан төшкәннәр, икенчесенә кадәр өч сәгать вакытлары бар. Универсиада, чемпионатлар белән бар дөньяга танылган Казаныбызны күрәселәре килә боларның. Тарихы белән дә кызыксыналар, милли ризыкларны да авыз итәргә исәпләре. Озын сүзнең кыскасы, берьюлы берничә көймәнең койрыгын тотарга уйлыйлар.

Йолдыз ШӘРАПОВА

Такси тотып вокзалга килгәндә, кунакларымның маршруты билгеле иде инде. Күптән түгел генә хезмәттәшләрем белән бергә сыйланып кайткан «Казанское» кафесына киттек. Ул Казанның нәкъ тарихи үзәгендә урнашкан, Кремль дә кул сузымы гына. Теләсәң, университетның ак колонналарын күреп килергә дә була. Милли музей да юл уңаенда гына.

Кафенең икенче катка илткән баскычыннан күтәрелгәндә үк татар моңы тылсымы бөтереп алды. Танышларым – башка милләт кешеләре, ләкин татарларны бик хөрмәт итәләр. Кафенең шул рәвешле татарча каршылавы кунакларымның күңеленә дә хуш килде. Ә мин исә, хуҗа кеше буларак, милли горурлык хисләре кичердем. Биредә булган арада бу горурлык хисен әллә ничә кат татырга туры килде.

Кафенең ишегеннән кергәч тә, кунакларым: «Безнең тамак ачкан иде бит, ә син китапханәгә алып килдең бугай?» – дип, сораулы караш ташладылар. Чынлап та, болай уйларга җирлек бар: кафенең диварларына иске газеталардан кисеп алынган мәкаләләр ябыштырылган, тәрәзә төпләрендә Казан тарихына багышланган китаплар куелган. Өстәлләрнең өслегенә шәһәребезнең үткәне, танылган шәхесләренең фотосурәтләре ясалган, кыскача биографияләре язылган. Ризык әзер булган арада карарлык нәрсәләр шактый монда.

Бәхет тәмам басты кунакларымны – балалары шул ук бинада үтә торган квестка китте. Замана малай-кызларының вакытларын ярату үткәрә торган шөгыле ич бу. Элеккеге Казан дигән урамда борынгы бай йортында урнашкан әлеге үзенчәлекле кафенең студентлар үткәрә торган квесты да башкалабыз, Татарстаныбыз тарихына багышланган. Без сөйләшеп утырган арада, тутырылган үрдәк, зәвыклы итеп бизәлеп, табынга да килде. Матур гына түгел, тәмле дә иде ул. Яңа елны искә төшереп, хуш исләрен таратып, бәйрәм рухы өстәде. Гадәттә, мондый каз-үрдәкне зур бәйрәмнәр алдыннан яки туй-никах ише олы танталарга пешерәләр. Безнең дә бәйрәм бит – күптән очрашмаган якын дуслар бер табын артында гөрләшеп утырабыз. Ул арада кунакларымның улы белән кызы квесттан кайтып, табынга кушылды. «Вакыт машинасына утырып, җиһанны коткарып» йөргән балаларның тамаклары шактый ачкан иде. Үрдәкнең сөяген дә тәмләп суырдылар. Анналары майда гына пешкән үтә күренмәле кош теле һәм баллы чәкчәк белән шифалы үлән чәе эчкәч, дөньялары тәмам түгәрәкләнеп китте. Ләкин санаулы вакыт бик тиз уза бит ул, безнеке дә чапты гына. Кафедан чыккач, шул ук бинада урнашкан һәм шуның белән бик җайлы булган (эзләп йөрисе юк) «Казан күчтәнәче» кибетенә кереп, «Сабантуй» дигән кайнатма белән шундый ук исемле матур каплы чәй алдылар. Мин дә бер савыт кош теле бүләк иттем. Табында бик яратканнар иде, сыйлансыннар безнең Казан күчтәнәче белән! Кибет киштәләрендә хуш ис аңкытып торган яңа гына пешеп чыккан бәлешләрдән (пекарнялары үзләренеке) дә баш тарта алмадылар. Башкалабызда санаулы вакытларын файдалы, кызыклы, тәмле һәм ямьле уздырган кунакларым өчен сөенеп йөрдем. Поездга утырып киткәнче, алар үзләре дә тәмле сәяхәт өчен мең кат-кат рәхмәт укыдылар.

Вакыт ачкычы кулыңда булса...

Кунакларымның рәхмәтен комплексның хуҗасына әйтергә тиешмендер инде дип уйлап, аны эзләп, кафега кабат киттем. Ул шунда булып чыкты. Танышып алгач, Мәдинә Сабирҗанга кунакларның әманәт рәхмәтен җиткердем һәм берничә сорау да бирдем.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

– Кафегызны тамак туйдыру гына түгел, ә рухи азык алырга да мөмкин урын итеп ясау уе каян туды?

– Миңа дөньяның шактый илләрендә булырга туры килде. Турист бит ул шул кыска гына вакыт эчендә әлеге илнең тарихын да белергә, матур урыннарында булып, фотога да төшәргә, ризыгыннан да авыз итеп өлгерергә тели. Элек киштәдә тузан җыеп ята торган сувенирлар алып кайта идем. Соңрак шул илнең аңа гына хас күчтәнәчен алып кайта башладым. Бу танышларыма, өйдә калганнарга аеруча ошады. Һәм шунда башыма бер фикер килде. «Безнең Татарстанга, Казанга да туристлар күпләп килә бит. Кайтып киткәндә күчтәнәчкә нәрсә алып кайта алалар соң алар? Шул бер әлеге дә баягы чәкчәк инде. Ә бит безнең халыкның көн буена тамагыңны тук итәрлек итле-майлы ризыклары да, телеңне йотарлык баллы ашамлыклары да күп. Бәлки, шулардан авыз иттерә торган берәр кафе ачып җибәрергәдер дип уйлап йөри башладым. – Без кемнән ким!»

Мәдинә ханым – Казан кызы, башкаланың 15нче гимназиясен тәмамлаган. Кечкенәдән татар моңын тыңлап, милли ризыкларыбызны ашап, җырлап-биеп, җанына татар рухын җыеп үскән кыз озын-озак уйлап тормый, тәвәккәлли. Рәсми документларны эшләргә университетта алган юрист белеме ярдәм итә. Менә шулай итеп, 2013 елда Универсиада башланырга санаулы гына көннәр калганда, ишекләрен ача кафе. Корабтан балга дигәндәй, кечкенә инешләрдә йөзеп тормастан, олы океанга чумарга туры килгән аңа – Универсиада кунакларының тамагын туйдыруда ул да катнашкан.

– Ризыкландыру бик җаваплы эш бит. Сәламәтлеге төрле хәзер кешенең, аллергиклар да бар. Ә инде бөтен дөньядан җыелган халыкның тамагын туйдыру аерата җаваплы эш. Куркытмадымы?

– Әйе, зур җаваплылык тоеп, бөтен тырышлыкны куеп эшләдек. Үзем дә, хезмәттәшләрем дә. Килгән кунаклар башта ризыкларыбызны, шуның аркасында аннары Казаныбызның үзен яратсыннар, тагын килсеннәр дип тырыштык. Хезмәтең кешене сөендерә алса, яңа эшләргә дәртләнәсең ич ул. Бер ел элек күчтәнәч кибете ачтык, барысы да туристлар өчен инде. Казаныбыздан матур тәэсирләр белән китсеннәр өчен, шул ук вакытта Казан кешеләре дә кафебызга килеп утырсалар, файдалы булыр, чөнки күпләр тарихны да, шәхесләрне дә начар белә.

– Квестыгыз да бар икән, ул да шул тарихны өйрәтер өчен оештырылдымы?

– Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, диләр. Ә мин Казаныбызның киләчәге матур булуын телим. Соңгы араларда модага кергән квестларда да, кеше вакытын файдалы итеп уздырсын дип, тарихка багышланганын сайладык. Студент егетләр Антон һәм Артур белән бергә катнашучылар вакыт ачкычын эзлиләр. Зилант, Шүрәле белән дә очрашалар, Сөембикә тарихы белән дә танышалар. Чапанлы-чалмалы аксакал ясап биргән шифалы чәйне дә эчәләр. Ә иң мөһиме, шулай уйнап-көлеп, Татарстаныбызның бай тарихы белән танышалар.

Кеше өчен иң кыйммәт кадерле әйбер бүгенге көндә ул – вакыт. Һәркем шул вакыт җитмәүдән иза чигә. Шуңа күрә дә һәркем бер атуда ике куян, берьюлы икеөч көймәнең койрыгын тотарга тырышып яши. Бүтәнчә булганда, тизлеген көннән-көн арттыра барган тормыш арбасыннан төшеп калуың да озак түгел. Менә шуны аңлаганнар, үзләренең дә һәм бүтәннәрнең дә вакытының кадерен белгәннәр зур уңышларга ирешә дә инде бүген. Яңа танышым да, рәхмәт, шундый булып чыкты.

ИЛГИЗӘР

Азат Кашапов: «Нәрсәгә дә булса ирешү өчен, эшләргә генә кирәк»

Азат Кашапов – гап-гади Казан кешесе. Әмма ул ике ел эчендә 13 илгә сәяхәт иткән: Америкада акча эшләгән, Һиндстанда балалар укыткан, Польша, Японияда белем алган. Казан федераль университетының Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе (ИТИС) студенты алдында бернинди чикләр дә, чикләүләр дә юк кебек.

Алисә САБИРОВА

– Азат, сәяхәттә иң мөһиме – тәүге адым, диган идең. Шәхсән үзеңә беренче адымны ясарга нәрсә этәрде?

– Беренче курста укыганда, уку белән өй арасында гына йөрдем. Гади студент идем. 2014 елның җәе тормышымны тулысынча үзгәртте. Нәкъ менә шул вакытта «Сәләт» лагере, «Селигер» форумы белән таныштым. Анда AIESEC волонтерлар оешмасы турында белдем. Шуның аша 2015 елның гыйнварында Һиндстанга китеп тә бардым. Волонтер буларак, Дели шәһәрендә балаларга инглиз теле һәм математика фәнен өйрәттем. Ике айга сузылган сәяхәт вакытында тугыз шәһәрдә булдым. Волонтер булгач, эш өчен акча түләмәделәр, ләкин яшәү һәм ашау бушка иде.

– Беренче сәяхәтеңә бераз тукталып китик әле. Нинди ул Һиндстан?

– Һиндстан – контрастлар иле. Бездә бөтен кеше дә матур киенергә, яхшы яшәргә тырыша. Ә анда социаль катламнар арасында аерма күзгә бәрелеп тора. Әйтик, сәүдә үзәкләрендә матур киенгән кешеләр күрсәң, аннан чыгуга инде «тук-тук» диган таксиларда эшләүче ярлы шоферларга юлыгасың.

– Анда сәяхәт итүгә күпме акча тоттың?

– 80 мең сум тирәсе. Бер караганда, бу – шактый зур сан. Әти-әнигә рәхмәт, алар ярдәм итте. Үземнең дә бераз җыйган акча бар иде. Әгәр дә шушы беренче адым булмаса, башкалары да булмас иде. Монда чит илдә яшәү тәҗрибәсен алдым, инглиз телемне шомарттым, үзем кебек башка студентлар белән аралаштым, яңа проектлар белән таныштым. Шуңа да, чыгымнарга карагандa, сәяхәтемнән уңай яклары күбрәк булды. Һиндстан – сәяхәтләр тарихыма салынган беренче кирпеч.

– Бу ике ел эчендә үзең өчен нинди ачыш ясадың?

– Тормышта бар да мөмкин икәненә инандым. Әгәр ике ел элек, кыска гына вакыт эчендә 13 илдә буласың дисәләр, ышанмас идем. Миннән хәзер еш кына: «Ничек сәяхәт итеп була?» – дип сорыйлар. Дөресен генә әйткәндә, һәркем бу сорауга җавапны үзе дә белә. Ләкин алар аны эшләми. Нәрсәгә дә булса ирешү өчен, бары тик аны эшләргә генә кирәк икәненә төшендем.

– Кайбер кешеләрдә тел белмәү чикләве бар.

– Мин дә, Һиндстанга килгәндә, инглизчә яхшы сөйләшми идем. Лицейда инглиз теле белән мөнәсәбәтләрем яхшы булмады, дөресрәге, инглиз теле укытучысы белән. XI сыйныфның соңгы чирегендә чиреккә беренче тапкыр «өчле» дә чыкты әле. Суга кергәч, йөзәргә өйрәнәсең, диләр бит. Хәзер исә инглиз телен башкаларга да өйрәтәм.

– Иң истә калган ил нинди булды?

– АКШ булгандыр. Ул илдә бар да бар кебек. Бөтен җир матур, чиста, йортлар океан буенда урнашкан. Бәяләр белән чагыштырганда, хезмәт хакы югары. Мин анда «Work and travel» («Эш һәм сәяхәт») программасы буенча барган идем. Бер украина ресторанында пешекче булып эшләдем.

– Андагы гади халык Россия турында ни уйлый?

– Америка кешесе безнең турында да, башка илләр турында да артык уйламый. Сәясәт белән дә кызыксынмый. Аның өчен үз иле идеаль.

– Американы мөмкинлекләр иле диләр, бу чыннан да шулаймы?

– Чыннан да, бу шулайдыр. Америка турында күп кеше хыяллана. Хезмәтеңә карап бәялиләр анда. Күбрәк эшләгән саен, күбрәк аласың. Ә бездә арттан этеп торучы булмаса, ничек тырышсаң да, өскә күтәрелүе авыррак.

– Хәзер син үзең дә студентларга читкә чыгып китәргә ярдәм итә башлагансың икән.

– Студентларның сәяхәтләр буенча «белешмә кенәгәсе» мин хәзер *(көлә)*. «Work and travel» программасы буенча Америкага китәргә ярдәм итәм. Студентларга башта нинди максатларда һәм кая барасын ачыкларга киңәш итәм. Чит илдә волонтер буласыңмы син, укыйсыңмы, эшлисеңме – һәрберсенә төрле программалар бар. Шул программаларга нигезләнеп, илне сайлыйсың һәм кирәкле документларны җыя башлыйсың.

– Студент булмаган кеше минималь чыгымнар белән сәяхәт итә аламы?

– Мин Һиндстанга барган AIESEC волонтерлар оешмасы белән төрле илләрдә волонтер булырга мөмкин. Югары белем алган дипломыңны тотып, тагын берәр чит ил университетына укырга керә аласың. Сиңа әле укыган өчен күп итеп стипендия дә түлиләр.

– Хәзерге вакытта КФУдан тыш, син әле Япониядә дә белем аласың икән.

– Әйе, анда социаль фәннәр өйрәнәм. Программистлыкны сайламадым, башка өлкәдә белем аласым килде. Әлегә Японияда артык сәяхәт итә алмадым. Цукуба, Токио кебек шәһәрләрдә генә булдым, тауларга мендем. Америкадан кайткач, бер айдан Япониягә чыгып китәргә туры килде. Алар бер-берсеннән шактый аерыла. Америкада кешеләр ачык, һәрвакыт елмаеп торса, Японияда, киресенчә, үз-үзенә бикләнгән, чит кешеләр белән аралашырга атлыгып тормыйлар. Метрода берәр кешегә «гафу итегез» дип эндәшсәң дә, алар сискәнеп китә.

– Иң кыйммәтле ил кайсысы булды?

– Норвегиядер бәлки. Россия белән чагыштырсак, кайбер әйберләр анда сигез тапкырга кыйммәтрәк. Алар үзләре дә сәгатенә 2000-2500 сум акча эшли.

– Сәяхәт төрле бәла-казалар да китереп чыгарырга мөмкин бит әле. Чит илдә берәр хәл булса, кая мөрәҗәгать итәргә?

– Чыннан да, кисәк кенә авырып китсәң, син, үз илеңдәге кебек, теләсә кайсы хастаханәгә барып дәвалана алмыйсың. Шуңа да сәяхәтләргә киткәнче, иң беренче чиратта гомереңне иминиятләштерергә кирәк. Берәр хәл килеп чыкса, дәвалану чыгымнарын капларга җиңел булачак. Әгәр дә юлда акчаңны, паспортыңны урласалар, һәр илдә Россия вәкиллеге бар. Алар сиңа ничек булса да ярдәм итәргә тиеш.

– Киләчәккә нинди планнар?

– Казанны сагындым. Киләчәктә Казанда торып, монда үз эшемне башлап, аена бер тапкыр чит илгә чыгып керергә уйлыйм. Америкага тагын бер тапкыр барып кайтыр идем. Көнбатыш Европа, Көньяк Америка, Африка, Австралия кебек әле мин булмаган континентлар калды.

Туган шәһәре – Казан.
Туган көне – 30 ноябрь, 1994 ел.
Яраткан китабы – Теодор Драйзер «Трилогия желаний».
Кызыксынулары: спорт (академик ишү, футбол, пауэрлифтинг), видеоблогинг.
Тормыш шигаре: «Тиеш әйберне эшлә – ни булса, шул булыр».

«WORK AND TRAVEL» ПРОГРАММАСЫНДА КАТНАШУ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ ДОКУМЕНТЛАР

1. **Чит ил паспорты (срогы бер елдан да ким булырга тиеш түгел).**
2. **Үз университетыңның деканатыннан көндезге бүлектә укуыңны дәлилләгән белешмә.**
3. **Студент билетыңның күчерелмәсе.**
4. **Инглиз телендә язылган резюме.**
5. **J-1 студент визасы.**
6. **Job Offer – чит илдә сиңа эш тәкъдим итүче оешмадан эшкә чакыру хаты.**

(Программада катнашу өчен сентябрь башыннан март ахырына кадәр гариза тапшырырга кирәк)

Ата йөрәге таудан өлкән

Атасы барның бәхете бар, диләр безнең халыкта. Бу сүз минем өчен бигрәк тә әһәмияткә ия. Мин – бәхетле бала, әнине кечкенәдән югалтсам да, ятимлек ачысын тоеп үсмәдем. Янымда һәрвакыт аңлаучы йомшак күңелле, тәмле сүзле әтием булды.

Әтием – Хөснетдинов Хәмит Абдулла улы. Ул 1963 елның 14 февралендә Аксубай районы Иске Кызылы авылында туган. Хәзерге вакытта Түбән Кама шәһәрендә гомер итә.

Әтием белән әнием яратышып 1984 елда өйләнешәләр. Бәхетләрен түгәрәкләндереп, бербер артлы ике бала – абыем белән мине алып кайталар. Аңлашып, чөкердәшеп матур гына гомер иткәндә, аяз көнне яшен суккандай куркыныч хәбәр әйтәләр: әниебез – терелмәслек авыру. Даруларның, табибларның файдасы булмый. Тол калганда, әтиебезгә бары 37 яшь була. 34 яшьлек әниебез үлгәндә, миңа – 11, ә абыема 14 кенә яшь иде. Бу югалтуны без бик авыр кичердек. Безне курку алды: алга таба әнисез ничек яшәрбез, юатучыбыз, тәрбияләүчебез хәзер кем булыр?! Моңарчы әни җилкәсендә булган өйдәге тавык чүпләп бетермәслек эшләрне ничек башкарып чыгарбыз? Бәхеткә, әти үзен кулга тиз алды: барлык өй эшләрен үзе эшли башлады һәм бер дә сынатмады – ашарга да пешерде, керен дә юды (ул вакытта автомат машиналары юк иде), хөкүмәт эшенә дә җитеште. Абый белән миңа авыр эш кушмаска тырышты. Әтиебез бәлешләр дә сала, токмач та кисә, коймагын да пешерә. Кулыннан килмәгән эше юк, оекбашларга ямаулыкларга кадәр салды. Төзүче дә, пешекче дә, тегүче дә, сантехник та, слесарь да була алды ул. Шул ук вакытта, әкренләп, безне дә тормыш серләренә төшендерде: хезмәт сөяргә, хуҗалык эшләрен белергә, бала җанлы ата-ана булырга кирәклеген үз мисалында күрсәтте. Әни өйрәтергә өлгермәгән бар эшкә дә мине әтием өйрәтте. Бүгенге көндә ирем белән аңлашып яшәвемдә аның да өлеше зур: иремне, аның туганнарын хөрмәт итеп яшәргә кирәген дә ул аңлатты.

Әтиебез бик яшь тол калса да, балаларга авыр булмасын, безне кыерсытмасыннар дип, өйләнмәде. Хәзер инде мин тормышта, минем дә ике кызым бар. Абыем әти белән яши, намазга басты, әлегә өйләнмәгән. Инде без үскәч кенә, әтиебез үзенә тиң яр тапты. Аның ялгыз калмавына без бик шатбыз.

Әтиебез озак еллар төзелештә монтажчы булып эшләде. Эшендә дә аны һәрвакыт хөрмәт итте. Инде менә хәзер, без үсеп аякка баскач, ул да тиң ярын тапкач, тормышка куанып яшисе дә яшисе иде бит...

Тик бәла агач башыннан йөрми, диләр шул. Тормыш авырлыклары аның йөрәге өчен эзсез үтмәде, әтиебезгә 2016 елның июлендә бик каты инсульт булды. Без аның өчен бик борчылдык. Аллаһы Тәгаләдән аның терелүен сорадык. Аллага шөкер, хәзер инде әтиебез аякка басты. Авыр көннәр артта калды. Әтиебезнең бүгенге көндәге иптәше Нәҗибә апага да бик зур рәхмәт, абыем өчәр айга командировкага киткәндә, ул әтине карап-барлап торды. Аллаһы Тәгалә аңа да исәнлек бирсен.

Без абыем белән әтине бик хөрмәт итәбез һәм аңа барысы өчен дә рәхмәтлебез. Ул гомер буе без дип кенә яшәде һәм тиешле тәрбия бирде. Безнең өчен ата да, ана да була алды.

Әтиебез безгә бер вакытта да кул да, тавыш та күтәрмәде. Үтемле сүзе, ягымлы карашы, иң беренче чиратта, үз үрнәге белән тәрбияләде. Ул бик йомшак күңелле, ачык йөзле, барлык кешегә дә ярдәмчел. Һәрвакыт балалар дип яшәде, үзе кимәгәнне дә безгә кидерергә, үзе ашамаганны безгә ашатырга тырышты.

Әтием оныкларын бик ярата, алар белән очрашу көннәрен сагынып көтә. Тәмледән-тәмле күчтәнәчләр әзерләп торучы бабаларын кызларым да бик хөрмәт итә.

Әйе, ата-анаң исән-сау булу – зур бәхет. Мондый бәхет һәркемгә дә тигез бирелми шул. Үз баласына бер үк вакытта ата да, ана да, якын дус та, сердәш тә була белгән аталар зур ихтирамга лаек. Минем дә таудай олы йөрәкле, кешелекле, шәфкатьле атам алдында башымны иясем килә. Тормыш булгач, гел матур сүзләрне әйтеп тә бетерергә вакыт тапмыйбыздыр, яннарында озаклап утырып серләшкән минутлар да сирәк була торгандыр, шулай да минем һәр туар көнем иң якын кешемә исәнлек теләп башлана. Гомерләрен озын ит, сәламәтлеген ныклы ит, Раббым! Бар теләгем: әтиебез тыныч, рәхәт тормышта безне куандырып озак яшәсен иде!

Чулпан ГЫЙЛЬМАНОВА,
Түбән Кама районы,
Шәңгәлче авылы.

Кадерле укучыларыбыз!

Килгән хатларның күплеген искә алып, бәйгене 30 апрельгә кадәр озайтырга булдык.

Җәмгыятьтә Әти ролен күтәрүгә, үрнәк гаиләләрне барлауга юнәлтелгән бәйгедә теләге булган һәркем катнаша ала. Моның өчен Әтиләрне данлаган язмаларны «Шәһри Казан» редакциясенә юлларга кирәк. Шигырьләр кабул ителми. Конкурста 3 номинациядә 3 җиңүче бүләкләнә. Җиңүчеләр әтиләре белән бергә Казанга чакырыла. Бүләккә – өч велосипед!

Мин – Рәшит кызы

Әбием Фатыйма йөрәк астында 11 бала йөртеп, аларны дөньяга тудырган. Ул заманның төрле чирләреннән алты баласы мәрхүм булган. Бишесе – Рәйсә, Гөлсылу, Гөлбостан, Рафис, Рәшит исән сау булып үсәләр. Иң төпчеге, шугы, тересе – минем әтием Рәшит Гарипов.

Ул 1947 елның 25 гыйнварында туа. Төпчек булып озак иркәләнергә язмый аңа, 48 яшендә Хафиз бабам якты дөнья белән бәхилләшә. «Мин бик кечкенә идем, өч-дүрт яшь булыр, әтинең йөзен күз алдына китерә алмыйм, чалымнары гына хәтердә: ул озын буйлы, бик матур гәүдәле кеше иде. Базардан кайткан чагын хәтерлим, кишер алып кайткан иде», – дип искә ала әтием әтиле чагын. Ятимлекнең ачысын күреп, юклык, авырлык белән үскәнгә бик яшьли кул арасына кереп, эшкә бик тырыш, таза, матур гәүдәле егет булып җитә. Әтиемнең куллары чынлыкта да «алтын». Агач, тимер, таш эшләрен дә җиренә җиткереп башкара. Без өч бертуган, үскәндә, кеше яллап эшләткәнне хәтерләмим. Югары уку йортларын тәмамлаучылар бүген бик күп, ләкин «авыл университеты»ның барлык имтиханнарын тапшыра алучылар гына авыл тоткасы була ала торганнардыр. Әтием әнә шундыйлардан.

Мин үземне белгәннән бирле безнең хуҗалыкта ат булды. Әлегрәк ул колхозныкы иде, аннан соң үзебез асрый башладык. Ат арбасы, чанасы, дугасы – боларның барысын да әтием үзе ясый торган иде. Балта сапларга, чалгы кырырга, бура бурарга, терлек суярга – саный китсәң, әтиемнең бары тик «бишле»гә генә башкара торган эшләре бихисап. Җәй көне печән өстендә, кышын ат чанасында әтинең куенына сыенып баруның рәхәтлекләре, әнием Рузилә белән бик тә гади, шул ук вакытта үтә дә экзерсез мөгамәләләре... Болар барысы да минем бала чагымның якты хатирәләре.

Һәр кеше өчен төп нигез дигән төшенчә бик тә газиз, мөһим. Бу синең әби-бабаңнан, әти-әниеңнән калган төп мирас, сине үстергән оя. Тәрәзәләрендә ут кабынмаган, капкалары бикле йортлар янәннан үтеп киткәндә, җаннар өшеп куя. Татар авылларында төп нигезне саклау бурычы ир-егетләргә тапшырылган. Әтием әнисе Фатыйманы гомере буе кадерләп яшәде. Бервакытта да әбигә каршы килгәнен, рәнҗеткәнен белмим. Бүген инде әти белән әни үзләре уллары һәм киленнәренә, оныкларына ярдәм итеп, киңәшләрен биреп яшиләр. Шөкер, буыннар чылбыры өзелми, дәвам итә. Безне дә ул орышмыйча, тормыш юлын үзебезгә сайларга мөмкинчелек биреп үстерде.

«Кыз туганыңның бусагасы алтын булса да, ир баладан сәдака тиеш» дигән гыйбарәне онытмады ул. Аның бу матур сыйфаты үзенең дәвамы булган абыем Рәискә дә күчкән. Апам белән без – туган нигездә һәрвакыт кадерле кунак.

Уйлыйм да хәйран калам: гап-гади авыл агае бу тиклем зирәклеккә, тормыш фәлсәфәсенә кайлардан өйрәнеп бетә алды икән? Мине авылдашларым Рәшит кызы дип йөртәләр. Моннан да зур бәя була ала микән?

Гөлназ ШАКИРҖАНОВА,
Балтач районы, Куныр авылы.

Менә шундый ул минем әти

Кайчак дусларым белән сөйләшкәндә «Мәктәпне тәмамлагач, кем булырга?» дигән сорауны кузгатабыз. Кемнеңдер – банкир, кемнеңдер – программист, ә өченче берәүнең артист буласы килә. Ә минем исә, нинди юлдан китсәм дә, иң беренче чиратта әтием кебек буласым килә.

Әтием Булат Мөхәммәдиев Түбән Кама шәһәрендә «Татнефть-Нефтехим» идарәче компаниясенең житештерүне автоматлаштыру бүлегендә әйдәп баручы белгеч булып эшли. Әтием белән әнием бергә 1993 елда КФУны тәмамлаганнан соң килеп урнаша. Әтием үзенең хезмәт биографиясен данлыклы шиннар җитештерү заводында башлап җибәрә һәм бүгенге көнгә кадәр (заводның исеме берничә тапкыр үзгәртелсә дә) шунда эшләвен дәвам итә. Эшеннән аның кебек тәм табып эшләүчеләр сирәктер. Катлаулы отчетлар төзү, программалар язу, автоматлаштыру системаларының өзлексез эшен контрольдә тоту – аның төп бурычларының бер өлеше генә. Остаз буларак, һөнәр көллиятләрен тәмамлап килгән яшь белгечләргә үз эшенең серләрен төшендерергә дә булыша ул. Тик аны кайчак яшьләрнең үз эшләренә җавапсыз караулары борчый. Эшен яратып, җиренә җиткереп башкармаган кешегә һөнәрен алыштырырга кирәк дигән фикердә ул.

Өебездә дә әтиемнең эшсез торганы юк. Ялгыз күрше карчыгына ярдәм итәргә дә җитешә. Матур итеп рәсем дә ясый, аяк киемнәрен төзәтергә дә булдыра. Кичләрен исә, еш кына, кулына баянын алып, халкыбызның моңлы көйләрен суза. Безне дә җырлатып-биетеп ала.

Әтием ничек укуым белән һәрчак кызыксынып тора, ата-аналар җыелышларына даими йөри. Хәтеремдә: әти мине балалар бакчасына йөргәндә үк шахмат уйнарга өйрәтте. Укырга кергәч, шәһәр күләмендәге шахмат ярышларында катнашып, урыннар алганым булды. Җәйләрен без бергәләп ямьле Ык буенда балык тоту ярышлары үткәрәбез, кышын чаңгыда йөреп ләззәтләнәбез. Әтием һәр нәрсәдән хәбәрдар. Ул безне дә бер нәрсәгә дә битараф булмаска өнди. Бүгенге көндә абыем Илназ укуын кызыл дипломга тәмамлап, әйдәп баручы предприятиедә яхшы гына эшли икән – монда да, һичшиксез, әтиемнең дә өлеше бар.

«Кеше бәхетле булсын өчен өч нәрсә кирәк: берсе – сәламәтлек, икенчесе – гаиләдә тынычлык, өченчесе – яраткан эшең булу», – ди минем әти. Тик соңгы елларда сәламәтлегенә шактый зыян килде. Шуңа да карамастан, без аның һичкайчан күңел төшенкелегенә бирелгәнен, кәефсезләнгәнен, дорфаланганын, тәмсез теләнгәнен күргәнебез юк. Аны гаиләдә генә түгел, туганнарыбыз да, хезмәттәшләре дә хөрмәт итә.

Айсылу МӨХӘММӘДИЕВА,
Түбән Кама.

Ике кат ныгытылган никах

ГАИЛӘ

Журналист Альбина Гарифуллина Африка егете Амадуга кияүгә чыккач, аларның гаиләсе турында язмаган газета-журнал калмаган иде. Шушы көннәрдә аларның өйләнешүенә 16 ел булды. Шул уңайдан без Дяхателар гаиләсенә кунакка барып кайттык.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

МӨСЕЛМАННАР ГАШЫЙК КЫНА БУЛМЫЙ, ӨЙЛӘНӘЛӘР ДӘ

«Әле дә яңа гына өйләнешкән парлар кебек яшибез», – дип каршы алды алар безне. Сүзебез Альбина белән Амадуның танышу тарихыннан башланды.

– Бу хәл көтелмәгәндә булды. 29 яшемдә булсам да, кияүгә чыгарга ашыкмый идем. «Эфир» телеканалында барган «Будем здоровы» тапшыруына СПИД турында сюжетлар төшерергә дип, Африкага бардым. Язмыш кушуы буенчадыр инде, бу минем Сенегал иленә икенче баруым иде. Кабат шунда барырга уемда да юк иде югыйсә. Беренчесендә дә озак кына вакыт иганәчеләр эзләргә туры килде. Бу юлы исә минем үземнән, нишләп тагын бармыйсың, кызыклы сюжетлар төшереп алып кайткан идең бит, дип сорадылар. Акча юк дигәч, иртәгә кил, акча табарбыз, диделәр. Сенегалдан чакыру да озак көттермәде. Язмыш дими, ни дисең?! Барысы да җай гына барды. Шулай итеп, бер дә уйламаганда, мин кабат Дакарга киттем. Анда шактый гына тоткарланырга туры килде. Без очрашасы профессор бер атнага Италиягә командировкага киткән булып чыкты. Буш вакыт шактый иде. Шәһәр белән дә таныштым, кунакка да йөрдем. Мин яшәгән гаиләнең җиде кызы бар иде. Алар әкәм-төкәм кабырчыгы белән багалар. Миңа да, тиздән туең була, дип юрадылар. Мин, әлбәттә, моңа бөтенләй ышанмадым, көлеп кенә куйдым. Шушы кызлар мине бер танышларына кунакка алып барды. Анда бөтен гаиләдә дә балалар күп, барысы да зур-зур йортларда яши. Бу йортта да кызлар күп, бер абыйлары да бар икән. Без килгәндә, ул йоклый иде. Ишегалдында чәй эчеп утырабыз шулай, ишектән, елмаеп, Амаду чыгып килә. Чыпчын кояш инде менә. Бер күрүдә үк гашыйк булдым дип әйтә алмыйм, әмма шул ихластан елмаюы белән үзенә җәлеп итте. Үзара аралаша башладык, сөйләшергә уртак темаларыбыз да күп иде. Дакар океан ярында урнашкан, бервакыт шулай яр буйлап озаклап йөргәч, аларга кайттык. Ул әнисе белән бакчага чыгып китте. Шуннан керде дә: «Пәнҗешәмбе өйләнешәбез», – ди. «Ә нишләп пәнҗешәмбе?» – мин әйтәм. «Алайса, җомга», – ди. Ә мин риза, дидем. Беркемгә дә шалтыратмадым, киңәшләшмәдем. Дөрес эшлимме дигән сорау да тумады. Мин ничектер язмышка да, Амадуга да, үземнең карарыма да нык ышандым. Амадуның әнисен дә, сеңелләрен дә, аларның үзара мөнәсәбәтен дә, гомумән ныклы гаилә икәнен күрдем һәм ышандым. Амадудан, нишләп шулай тиз өйләнешәбез, дип сорагач, ул: «Мөселманнар гашыйк кына булмый, өйләнәләр дә», – диде. Аның ышанычлы кеше булуы сөйләшүендә үк чагыла иде, – дип сөйли Альбина.

Амаду исә Альбинага беренче күрүдә үк гашыйк булган.

– Бер генә кызның да күңелгә шулай кереп утырганы булмады. Миңа аның тыйнак булуы һәм зәвык белән киенүе ошады. Башка кызлар кебек майка, шортыдан түгел иде ул, үзенә килешле бик матур озын итәкле сарафан кигән иде. Әмма ир-ат хатын-кызның тышкы кыяфәтенә өйләнми, ул үзе янында тормыш итәрдәй чын дус күрергә тели. Альбинада мин шуны күрергә өлгердем, – ди ул.

– Өйләнешкән мәлләрдә ул миңа еш кына, син минем дустым, дип әйтә иде, – дип сүзгә кушыла Альбина. – Мин моңа башта үпкәли, дустың түгел, хатының дип төзәтә идем. Аның сүзләренең хаклыгына тормыш итү дәверендә генә төшендем. Бәхетле гаиләнең нигезендә чынлап та бер-береңә хөрмәт ята.

«ИКЕ ТАПКЫР ТУЙ ИТТЕК»

Амаду белән Альбина, гаиләбезнең ныклыгы ике тапкыр никах укытып, ике тапкыр туй уздырганга да, дип шаярта. Никах укытканнан соң, Дакар мэриясенә барып, рәсми рәвештә язылышканнар, туй уздырганнар. Якыннарны гына чакырып, җиңелчә генә туй мәҗлесе ясыйбыз дигәннәр иде, анда 60лап кеше булды, дип искә ала Альбина. Биш көннән ул Казанга кайтып китә.

– Әнигә кияүгә чыгып кайтуымны әйткәч, аның беренче сүзе: «Кияү кайчан кайта, тизрәк өйгә ремонт ясарга кирәк», – булды. Абыем да, апаларым да минем шаккатыргыч хәбәремне бик тыныч кабул иттеләр. Шулай итеп, Амадуны каршы алырга әзерләнә башладык. Ул өч айдан килде. Икенче тапкыр туйны минем туган шәһәрем Түбән Камада үткәрдек, – ди Альбина.

«НУРЛЫ АМАДУ»

Шулай итеп, Дяхателар гаиләсе Казанда яши башлый. Амаду яңа илгә, яңа традицияләргә тиз ияләшә. Альбинаның әйтүенчә, ул бик кызыксынучан, шуңа өстәп, аралашучан да, кешеләрне ярата, аларга дустанә мөнәсәбәттә, киң күңелле.

– Күршеләр аны нурлы Амаду ди. Иртән очраган һәр күрше белән елмаеп исәнләшә, хәлләрен сораша, комплиментлар әйтеп китә. Кечкенә балалар аны күрсәләр, каршына йөгереп киләләр. Ул үзенең күңел җылысын башкаларга да тарата, – ди ул.

Телне өйрәнү дә аңа авыр булмаган, рус телендә иркен сөйләшә. Амаду фатир дизайны белән шөгыльләнә, аңа кадәр йортлар фасадын бизәүче булып эшләгән. Кекин йортын, Дәүләт музеен, шәһәр Ратушасын реставрацияләүдә катнашкан.

– Татарстанның шундый мәһабәт биналарын яңартуда катнашуым белән горурланам. Казан – тарихи, матур шәһәр. Татарларны бик хөрмәт итәм, алар тырыш, эшлекле халык, – ди Амаду.

«КОЧАКЛАШЫРГА ЯРАТАБЫЗ»

Дяхателарның Наил исемле уллары белән Әминә атлы кызлары үсеп килә. Гаиләбезнең ныклыгы икебезнең бер диндә булуында да, ди алар.

– Шуңа өстәп, икебез дә күп балалы гаиләдән, – дип өсти Альбина. – Гаиләдәге мөнәсәбәтләр, балаларны тәрбияләү мәсьәләләрендә әтиәниләр тәҗрибәсенә таянабыз. Бала тыныч, тату, мәхәббәтле гаиләдә тәрбияләнергә тиеш. Үзебез дә шундый гаиләләрдә тәрбияләндек. Безнең гаиләдә кочаклашу гадәте бар. Озатканда, каршы алганда гына түгел, тиктомалдан гына да бер-беребезне кочаклап китәбез. Бу бигрәк тә балаларга ошый, әтиәниләренең бер-берләрен һәм аларның үзләрен дә яратуларын күреп-сизеп үсәләр.

Наил белән Әминә әтиләренең туган теле булган волов телен дә, татарчаны да яхшы белә. Әтиләренең иле, андагы милли мәдәният белән кызыксыналар. Ике-өч елга бер тапкыр Сенегалга да барып кайталар. Балаларның анда да яшәп карыйсылары килә икән.

Киләчәкне әйтеп булмый, язмышыңа ни язылгандыр бит. Альбинаның да насыйбын океан артында очратырмын дигән нәрсә төшенә дә кермәгән, Амаду да татар кызына өйләнермен дип уйламаган. Тормышның аның һәркемгә үз исәбе...

КУНАК БҮЛМӘСЕ

Эльмира Кәлимуллина:

«Сәхнә – бокс рингы түгел»

Эльмира Кәлимуллина турында белмәүчеләр юктыр да инде ул. Шуңа да, чибәр, талантлы кызның «Голос» проекты аша танылуы, Татарстан Республикасының атказанган артисты булуы турында сөйләп тә тормыйм. Ә менә аның дуслары телендә «кудряш» булуы, әнисенең «йолдызлык чире» мәсьәләсендә куырып кына торуын, нинди сорауга беркайчан да төгәл җавап бирмәячәге – болар турында сер капчыгын тишсәк ярыйдыр...

– Эльмира, белүемчә, син музыкантлар гаиләсеннән түгел. Шуңа да ни рәвешле иҗат казанына килеп керүең, танылуың кызыклы – әти-әни хәер-фатихасындагы балачак хыялын тормышка ашыру булдымы ул, кем әйтмешли, йолдызлар кисештеме?

– Гаиләбездә музыкаль белеме булган кеше әниемнең сеңлесе генә иде. Әмма шуңа карамастан, авыз тутырып, гаиләмне музыкаль дип атарга хокукым бардыр. Дәү әнием миңа бишек җырлары белән үк ул орлыкны салды кебек. Әнием миңа мәктәптә җырлау өчен тавышыма туры китереп җырлар сайларга булыша иде. Хәтерлим әле, әни белән аның сеңлесе сөйләшәләр. Туган апам безне абыем белән музыка мәктәбенә йөртергә киңәшләр турында, бездә музыкаль күәс булуы турында тәкрарлый. Әнинең үз туксаны туксан – «Шәһәрнең икенче башындагы мәктәпкә ике баланы ничекләр йөртә алыйм ди мин!» Әмма сез әйткән йолдызлар кисешүедер инде – шул ук елның җәендә безгә шәһәрнең шул телгә алынган «икенче башына» күченергә туры килде. Музыка мәктәбе безнең күршедә генә булып чыкты. Башта сольфеджиода укыдым, хорга йөрдем. Соңрак минем белән индивидуаль рәвештә вокал белән шөгыльләнделәр, акрынлап конкурс һәм фестивальләрдә катнаша башладым.

– Һәм Эльмира шәһәр музыка көллияте студенты булырга уйлый башлады...

– Ә мине анда тавыш мөмкинлекләре җитеп бетми дип алмадылар. *(Көлешәбез!)* Шуңа мин, тынычлап, юридик лицейда укуымны тәмамладым, институтка икътисадчылык бүлегенә укырга керергә әзерләнә башладым. Мәктәпне тәмамлыйсы елны «Сандугач сайрар илем» исемле конкурста катнашу гына планнарны үзгәртте димме... «Татнефть» уздырган әлеге конкурсның гала-концерты Казанда «Пирамида» күңел ачу үзәгендә узды һәм мин анда Гран-при иясе булдым. Әлеге конкурстан соң Казанда еш булырга туры килә башлады. Нәкъ шул вакытта миңа күпләр музыканы ташламаска, киресенчә, профессиональ рәвештә шөгыльләнергә киңәш итте дә... Мин дә ул вакытта, күпләр кебек үк, югары музыка уку йорты – консерваториягә музыка көллияте белеменнән башка да кабул итүләре турында бихәбәр идем. Чынлыкта исә анда музыка көллиятеннән тыш та кабул итәләр, башта база белемен аласың, аннан кабат беренче курска кабул итәләр. Мин дә шул схемага таянып, Казан дәүләт консерваториясе студенты булдым һәм 2012 елда аны уңышлы тәмамладым. Шул ук елны «Беренче» канал «Голос» проекты турында хәбәр итте дә.

– Әлеге «Голос» проектын, аеруча үзебезнең якташлар чыгышыннан соң, күзәтмичә калган татарстанлы булмагандыр... Ә менәниләр сәхнә артында, кадр артында калды, Эльмира? Көнләшү, аяк чалулар булдымы?

– «Голос» проекты минем өчен ул иң беренче чиратта – мәктәп. Тормыш мәктәбе. Без бит барчабыз да кечкенә генә дөньяда яшибез. Гадәти кешеләр белән аралашабыз, гадәти эшләр белән шөгыльләнәбез дигәндәй... Ә монда минем өчен бөтенләй башка яссылык ачылды – телевизор экраныннан гына күреп белгән мега-талантлы башкаручылар синең белән янәшәдә эшли, сәхнәдә җырлый, синең осталыгыңны чарлый. Александр Градский, Леонид Агутин, Дима Билан, Пелагея исемнәре үзе генә ни тора?! Әлбәттә, әлеге җирлектә син бик тиз мобильләшәсең, андый осталар кулы астында тиз генә укырга, үзләштерергә өйрәнәсең. Әмма сәхнә арты тормышында сез әйткән көнләшү, аяк чалулар булды дип әйтә алмыйм. Киресенчә, без анда бер-беребез өчен борчылып, төшеп калганнар өчен елашып яшәдек төсле. Аннан, сәхнә бит ул бокс рингы түгел, анда көндәшне егып салырга кирәкми. Чыгып, үзең өчен җиреңә җиткереп җырларга гына кирәк.

– Ничек уйлыйсың, Эльмира, танылу өчен нинди шарт мөһим – күп вакытта талант өстенә тырышып эшләү генә дә җитми төсле, уңыш 32 тешең дә күрсәтеп елмаймасаааа...

– Бәлки, миңа ышанмаучылар да табылыр, әмма мин бервакытта да үз алдыма танылу бурычын куймадым. Аны ничек куярга кирәген дә белмим... *(Елмая.)* Миңа һәрвакытта да мөмкинлегем чигендә тырышып, әйбәт итеп җырлау мөһим иде һәм хәзер дә шулай. Әнием, укытучым һәм үзем өчен минем чыгыш канәгатьләнерлек булырга тиеш. Шул гына. Уңышка ирешү өчен алшарт дип шуны атар идем – үзеңне багышлаган эшеңне яратырга кирәк. Әлбәттә, ярату белән генә булмый. Һәр эштәге төсле үк, музыкада да тырышып эшләргә, күп эшләргә кирәк! Үзеңә ышану да, булдырачакмын, дигән шигарь дә комачауламый һәм Ходайның «амин» дигән сәгате көтәрмәячәк.

– Танылу Эльмираны нинди якка үзгәртте соң?

– Читтән яхшырак күренәдер инде анысы! *(Рәхәтләнеп көлешәбез.)* Әчке дөньям белән мин шул ук Эльмира. Әлбәттә, хәзер вакыты тыгызрак, эшләре күбрәк кеше. Чак кына башкарак ритмда да яшимендер... Әмма кабатлыйм, күңелем үзгәрмәде. Әгәр инде борын чөю мәсьәләсендә сорасагыз, минем әни белән, бик тырышсаң да, «йолдыз чире» белән чирләп булмый. Шундук шапылдатып җиргә төшерәчәк.

– Кайда күбрәк яшисең дип тә сорыйм әле, Эльмира, «инста бит»еңә күз салсаң, анда самолет күбрәк...

– Шулай ук мыни? Хәзерге вакытта мин Казан белән Мәскәүдә күбрәк яшимдер. Әмма бу туган шәһәрем – Түбән Каманы онытым яки яратмыйм дигән сүз түгел. Иҗатчы буларак, ике башкалада мөмкинлекләр күбрәк, шуңа күрә әлегә Казан һәм Мәскәү.

– Иҗатташ дусларың сине «Кудряш» дип атый, моның тарихы да бардыр әле...

– Моның бөтен хикмәте шул бөдрә чәчләр генә инде! Әллә ни кызык тарихы да юк. Үземне белә башлаганнан бирле мине «Кудряш» дип атыйлар да. Быел җәй БИМ-радиода Илнур Пухтов һәм Руслан Халитов белән «Отряд смешного реагирования» дигән программада без бер-беребезне кушаматлар белән атап эндәшә идек. Әлеге программа аша аудитория минем дә кушаматның Кудряш икәнен белде.

– Иҗатташ дуслар темасына тукталгач, сорыйм әле: бармы ул иҗатта ихлас дуслык?

– Әлбәттә! 100 процент! Без беренче чиратта кеше, аннан соң гына иҗади кешеләр. Мин, мәсәлән, консерваториядә бергә укыган төркемдәшләрем белән дус. «Голос» проекты финалистлары – Настя Спиридонова, Маргарита Позоян, Динә Гарипова белән аралашам. Композитор Эльмир Низамов минем дустым.

– Әти-әниең әлеге иҗат дөньясын тормыш векторы итеп сайлавыңны кабул иттеме, әллә башка төрле һөнәрле итәселәре килгән идеме?

– Аларга минем ни-нәрсә белән шөгыльләнүем принципиаль рәвештә мөһим түгел. Сәламәт һәм бәхетле булуым да җитә! Мин сайлаган тармакны да алар шуңа яратып кабул иттеләр, һәрвакыт ярдәм итеп, киңәшләрен биреп торалар. Алар икесе дә инженер, әнием инженер-укытучы булса, әтием – инженер-төзүче. Бертуган абыем – техник фәннәр кандидаты, укытучы. Минем өчен тормышта иң мөһим һәм иң кадерле шушы өч кешедән башка үземне күз алдыма да китерә алмыйм. Китерергә дә язмасын! Гаиләм минем өчен беренче урында.

– Егет белән кыз арасындагы хисләр, мәхәббәт темасына бераз кагылып үтеп, сорыйсым килә. «Мин сине яратам» дигән тирән мәгънә сыйдырган сүзнең синең тарафтан әйтелгәне булдымы? Гаилә кору өчен идеаль яшь бар дип саныйсыңмы?

– Мин искелек тарафдарыдыр инде, әмма «мин сине яратам» дигән сүзне беренче булып ир-егет әйтергә тиеш дип саныйм. Әлбәттә, гаилә кору турында да уйланганым бар – һәр кыз баланың кияүгә чыгасы, бәхетле оя корасы, балалар үстерәсе килә. Әмма бу сорауга кистереп җавап бирә алмыйм...

– Хәзерге вакытта иҗат мәсьәләсендә без белмәгән, ишетми калган борылышлар бармы? Күпләр иҗат өчен Мәскәүне кулайрак күрә – бу нәрсә белән бәйле?

– Бернинди компания белән дә рәсми килешү нигезендә эшләмим. Иҗат һәм оештыру мәсьәләсендә үзем йөрим. Әмма Мәскәүне иҗат өчен идеаль урын дип әйтә алмыйм анысы. Әлбәттә, ул төп башкала, анда иҗади тормышның пульсы, иҗатка кагылган һәр яңалык анда тизрәк барып җитә, тизрәк чынга ашырыла. Шәхсән минем мисалда исә идеяләремне Казанда чынга ашыру җиңелрәк. Бездә дә шәп студияләр, үз эшенең осталары бар. Аннан, без бит хәзер интернет заманында яшибез. Ә ул бөтен чикләрне бетерергә сәләтле. Мисалга, минем «В черном бархате» Казанда калыпка салынды, гитара солосы Мәскәүдә язылды һәм электрон почтадан мине «куып тотты».

Ә Казан тормышымда зур урын били тора. Озакламый «Наш Татарстан» дигән яшьләр форумы узачак, анда бер мәйданчыкта эшләячәкмен. Шулай ук мин – Казан марафоны һәм Дөнья чемпионаты-2018 илчесе. Моннан тыш, Казанда гаиләм яши, шуңа да монда еш булам, монда яшим дип саныйм.

– Эльмираның ничек ял итәргә яратуы турында белик тә...

– Төрлечә ял итәргә яратам. Минем өчен иң ял ул – дуслар белән озаклап кафеда утыру да, тынычлыкта ялгызым калып китап уку да, шәһәр буйлап паркта йөрү дә булырга мөмкин. Ә кайвакыт беркемгә берни әйтми, чемоданымны кыстырып, бөдрә чәчләремне тузгытып, яланаяк йөгерерлек ак комлыгы булган диңгез ярына да качарга мөмкинмен...

Әңгәмәдәш –
Гөлнара ҖӘЛИЛОВА.

Төшләр кошның аягына бәйләнгән

Төш күрү һәм аларны юрау мәсьәләләре адәм балаларын бервакытта да битараф калдырмый. Безнең халык төшләргә борынгыдан ук ышанып килә. Алар арасында хәтта махсус төш юраучылар да булган. Күргән төшеңне чит кешегә сөйләргә ярыймы? Начар төшләр күргән очракта нишләргә кирәк? Әлеге сорауларны без «Өмет» мәчете имам хатибы Равил хәзрәт Бикбаевка бирдек.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Төш юрау безгә Йосыф пәйгамбәрдән үк килә. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын хәтерлисездер. Бервакыт унбер яшьлек Йосыф кояшның, айның һәм унбер йолдызның үзенә баш июен күрә. Төшен әтисенә сөйләгәч, ул: «Син пәйгамбәр булырсың, зур дәүләт иясе булырсың, унбер туганың да сиңа, хөрмәт йөзеннән, баш иярләр», – ди һәм чынлыкта да шулай булып чыга. Поэмада төш күрү һәм аларны юрау, юраганнары юш килү эпизодлары бик күп. Поэманың асылы Коръәннең «Йосыф» сүрәсеннән алынган һәм ул сүрәдән без Йосыф пәйгамбәрнең төш юраучы булуын беләбез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.)нең дә төш күрүгә кагылышлы хәдисләре шактый. Ул иртәнге намазны укып кояш чыкканчыга кадәр мәчеттә кала торган булган. Сәхабәләреннән кайсыгыз нинди төш күрде, дип сорашкан. Үзе күргән төшләрен дә сөйләгән. Галимнәр әйтүенчә, пәйгамбәрләрнең төшләре вәхи, ягъни Аллаһтан килгән яшерен хәбәр булып санала. Сәхабәләргә ул бер төшендә сөт эчкәнен күрүен сөйли. Сөт хәтта бармакларымнан ташып чыкты, аны Гомәргә бирдем, сөтне ул да эчте, ди. Бу төшне нәрсәгә юрадыгыз дигән сорауга, бу сөт – гыйлем, Аллаһы миңа гыйлем бирде, мин аны Гомәргә бирдем, ди. Галимнәр Гомәрнең чынлап та зур гыйлем иясе булуын әйтә. Тагын бер төшендә Пәйгамбәребез кайбер кешеләрнең өсләрендәге киемнәре күкрәгенә кадәр генә, кайберләренең кендегенә кадәр булуын, ә Гомәрнең кияме исә асылынып баруын күрә. Моны сын ничек юрадыгыз дигәч, бу – диннең ныклыгы, ди. Кемдәдер диннең ныклыгы зәгыйфь, ягъни киеме кыска, ә Гомәрнең иманы нык, кияме хәтта сөйрәлеп бара дип шәрехли ул төшен. Төшләр өч төрле була: аларның беренчесе – Аллаһтан, икенчесе – шайтаннан, өченчесе табигый халәтне чагылдыра, төгәлрәге, көндез уйлаганнардан чыгып күрелгән төшләр. Аллаһы Тәгаләдән килгән төшләр күп очракта хәерле яисә хәбәр бирә торган, кисәтү төшләре булса, шайтаннан булганнары – кешенең күңелен төшерү, куркыту өчен. Пәйгамбәргә берәү, төшемдә, имештер, башым киселгән икән һәм ул алдымнан тәгәрәп барды, ди. Аңа җавап итеп, Мөхәммәд Пәйгамбәр, синең белән төшеңдә шайтан уйнаган, аны кешегә сөйләмә, ди.

– Хәзрәт, төш юрау һәр очракта да дөресме?

– Пәйгамбәребезнең шундый хәдисе бар: «Төш кошның аягына бәйләнгән, кешегә сөйләсәң, ул төшеп китә». Төшне сөйлисең булса, ышанычлы яки гыйлемле кешегә генә сөйләргә ярый. Теләсә кемгә сөйләмәгез.

– Куркыныч төш күргәндә нишләргә?

– Әгузү билләһи минәшшайтанир ражим, дип әйтәсең дә сул ягыңа өч тапкыр төкерәсең һәм икенче ягыңа борылып ятасың. Әгәр дә күңелең шуннан соң да тынычлана алмаса, тәһарәт алып, намаз укырга кирәк. Кайбер галимнәр «Аятел көрси» укырга киңәш итә.

– Төштә җаннар тоташа ала, диләр....

– Төшеңдә үлгән кешене күреп сөйләшсәң, җаннар күрешкән, дип әйтәләр кайбер галимнәр. Мәетләр төштә нәрсә турында да булса хәбәр дә итәргә мөмкин. Пәйгамбәребез, ахырзаман алдыннан шатландыра торган әйберләр күп булыр, дигән. Кешеләр, алар нәрсәләр соң, дип сорагач, ул, изге төшләр, диде. Дөнья бетәр алдыннан мөселманнар тормышка аша торган изге төшләр күрер. Яхшы төш ул – пәйгамбәрлекнең 46дан бер өлеше. Белүегезчә, пәйгамбәрлек – алдагы әйберне хәбәр итү. Яхшы төштә дә Аллаһы Тәгалә киләчәктә булачак бер әйберне хәбәр итеп куя.

– Мөхәммәд Пәйгамбәрне төштә күрү өчен махсус намаз укырга кирәк диләр, бу дөрес әйберме?

